Словесное и предметное понимание читаемого текста, органично соединяясь, обеспечивает логическое понимание, но и этого недостаточно для полноценного восприятия художественного текста, особенностью которого является образность, эстетическая мотивированность языковых средств. Неправомерно, ссылаясь на низкий уровень языковой подготовленности учащихся иноязычной школы, строить урок литературного чтения только на значительно адаптированных художественных текстах и ограничиваться их пониманием на информативном уровне. Учитель должен помнить о том, что возможности постижения эстетической функции слова заложены в лексико-тематической близости учебных и художественных текстов. Можно не просто сопоставлять основное и контекстовое, метафорическое значение слова, но и в самом учебном тексте, предваряющем чтение художественного произведения, воссоздать детали картины, которая могла быть жизненной основой поэтического образа.

Так, исходя из своих наблюдений, мы рекомендуем учащимся картины ˝зимней дороги˝ в стихотворении А.С.Пушкина ˝Зимняя дорога˝ описывать на основе таких деталей: ˝скучная, безлюдная дорога, голубой лунный свет, печальные песни ямщика˝, которые дают представление о том, что в эти ночи поэт особенно глубоко чувствовал свое одиночество. Эмоционально-образная картина стихотворения и эстетическое понимание художественного текста могут быть усилены демонстрацией слайдов с иллюстрациями, дополнительными комментариями учителя или информацией, подготовленной самостоятельно обучаемыми.

Если обратиться к учебнику ˝Русский язык˝, то в нем преобладают вопросы и задания по содержанию текста, представлены упражнения, нацеленные на закрепление речевых навыков [Джураева 2018]. Задания развивающего характера направлены на формирование умений и навыков аналитического чтения: умение выделить в тексте эпизод, факт, деталь; умение соотнести отдельные части текста, восстановить события в хронологической последовательности, если эта последовательность нарушена; установить зависимость одного факта от другого и т.п. Особенно эффективны задания, выполнение которых требует от учащихся опоры на их жизненный опыт.

Следует заметить, что содержание уроков литературного чтения базируется на учете возрастных особенностей читателя-подростка (стремление к самопознанию через освоение социально-психологического опыта человека, запечатленного в произведениях литературы; интерес к персонажам и т.п.) и уровня его языкового развития. При этом невозможно сокращение темпа накопления словарного запаса за счет углубления знаний о каждом слове, так как знания основного значения слова уже недостаточно. Ориентиром становится такой уровень знания слова, который гарантирует его правильное использование в различных видах речевой деятельности и обеспечивает понимание его эстетической функции в художественном тексте.

Тематический принцип организации учебного материала на уроках литературного чтения в соответствии с учебной программой для иноязычной школы способствует решению задач развития речи учащихся: тематическая обусловленность конкретизирует отбор лексики для активного усвоения, создается возможность необходимого числа повторений активизируемых слов; а разнообразие речевых ситуаций в пределах одной темы способствует формированию навыков неподготовленной речи.

Тематический принцип освоения литературного материала содействует возникновению и упрочению ассоциативных связей в памяти учащихся, что очень важно для понимания целого ряда явлений русской литературы, особенно классической. Например, изучая художественное творчество русских писателей, учащиеся ˝погружаются˝ в историко-литературный процесс, тем самым совершенствуя свои умения и навыки анализа и оценки художественного произведения с точки зрения эпохи, в которой творил писатель.

На уроках литературного чтения учащиеся не только читают текст и пересказывают его содержание, но и осмысляют жанровую и образную специфику произведения. Например, на уроке учитель может задавать следующие вопросы: как идея раскрывается через поступки и характеры героев; каково авторское отношение к героям; какова роль изобразительно-выразительных средств языка в тексте и пр. В связи с этим усложняются формы усвоения текста: учащиеся готовят ответы на вопросы, пересказывают текст по составленному плану, заучивают наизусть отрывки из текста, вследствие чего усложняются и задания, предшествующие анализу литературного произведения (мини-проекты, готовят презентацию и т.п.).

Анализ художественного произведения на уроках литературного чтения в иноязычной группе осуществляется в таких видах работы учащихся:

1) осмысление опорных глав, эпизодов, деталей;

2) выяснение функций пейзажа и описаний предметного мира;

3) анализ средств портретной и речевой характеристики персонажа и т.д.

Обращение к анализу текста для обучаемого не самоцель, а средство более глубокого усвоения содержания художественного произведения, средство понимания специ-

фики литературы как искусства слова. Учитель ˝выстраивает˝ свои наблюдения в аналитической системе, умело используя выразительное и комментированное чтение.

Уроки литературного чтения предусматривает и частичную работу с теоретико-литературными понятиями, такими как: рассказ, сюжет, композиция, лирика, эпос, драма и др. [Магдиева 2021: 88].

**Литература**

Андриянова В.И. Основные ориентиры современной образовательной политики / В.И.Андриянова // Проблема развития когнитивно-творческих способностей обучающихся в современных условиях. – Ташкент, 2018.

Джураева З.Р. Русский язык. Учебник для учащихся групп с узбекским языком обучения профессиональных колледжей / З.Р.Джураева. – Изд. 5-е, испр. – Ташкент: ˝Sharq˝, 2018. – 368 с.

Магдиева С.С, Лагай Е.А. Современные педагогические технологии на уроках русского языка и литературы: учебное пособие для учителей общеобразовательных школ Узбекистана / С.С.Магдиева, Е.А. Лагай. – Ташкент, 2021. – 146 с.

**Макарова Виктория Юрьевна**
Московский педагогический государственный университет
УДК 372.8

## Когнитивно-функциональное направление в методике обучения русскому языку

*когнитивно-функциональный подход, методика обучения русскому языку, художественный текст на уроках русского языка*

Когнитивная лингвистика изучает познание человеком через язык окружающей действительности, а также те когнитивные способности, которые такому познанию способствуют: обработка языковой информации (умение воспринимать, запоминать, использовать), установление связей между языковыми единицами, материализация ментальных действий с языковыми явлениями, вычленение, понимание и сравнительный анализ языковых и этнокультурных концептов. Когнитивная лингвистика изучает взаимосвязь речи и мышления, уделяя особое внимание языковой логике. Об этом писал лингвист В.А.Богородицкий, который сравнивал способы познания мира с помощью науки и поэзии. Ученый объяснял, что механизмы познания отличаются особенностями мышления: ˝…у одних лиц мысль является с большей образностью составляющих ее представлений и понятий, у других же – с большей отвлечённостью˝ [Богородицкий 1909: 311].

Методика обучения русскому языку всегда опиралась на современные достижения науки о языке, чтобы внедрять новые интересные идеи в школьное образование и соответствовать требованиям времени. Когнитивное направление в лингвистике в этом плане для современной методики обучения русскому языку в школе можно считать новым, актуальным и перспективным.

***Когнитивный подход*** в обучении можно разделить на следующие элементы: функциональный, коммуникативный, семантический, системный [Дейкина 2019: 104]. Одним из самых перспективных в обучении русскому языку нам представляется ***когнитивно-функциональное*** направление.

Одним из крупных ученых-когнитивистов, работавших в русле данного направления в лингвистике, была Е.С.Кубрякова. Основные положения современного состояния лингвистики она описала в статье: ˝Об установках современной науки и актуальных проблемах когнитивной лингвистики˝ [Кубрякова 2004: 16], где выделила две функции языковых явлений: когнитивную и коммуникативную. Первая функция, по мнению ученого,

иллюстрирует роль языка в процессе познания действительности, а вторая помогает осознать, как функционируют определенные языковые единицы в языке и речи.

Совместить эти две функции возможно, если правильно подобрать дидактический материал к уроку. Вообще дидактический материал всегда подбирается в соответствии с темой урока русского языка, но в данном случае необходимо также уделить внимание функциям изучаемых языковых единиц. Какой дидактический материал выбрать, чтобы совместить процессы познания с осмыслением роли языковых явлений? С нашей точки зрения, таким дидактическим материалом является художественный текст. Чтобы проиллюстрировать высказанную мысль, рассмотрим обращение к стихотворному тексту на уроке русского языка в 5-м классе. Тема урока ˝Полные и краткие прилагательные˝ [Русский язык 2012: 91].

**Цели урока:**

1. Проверка степени усвоения признаков прилагательных. Организация самостоятельной исследовательской деятельности учащихся с помощью проблемных заданий на основе поэтического текста. Развитие коммуникативной компетенции (устной и письменной речи учащихся)

2. Воспитание эстетических чувств учащихся.

**Ход урока**

**Этап мотивации:** прочитайте выразительно отрывок из поэмы Некрасова ˝Мороз, Красный нос˝. Закройте глаза, представьте молодую крестьянку. Опишите героиню вслух (устно).

Красавица, миру на диво,
Румяна, стройна, высока,
Во всякой одежде красива,
Ко всякой работе ловка.
И голод и холод выносит,
Всегда терпелива, ровна...
Я видывал, как она косит:
Что взмах — то готова копна!
…Тяжелые русые косы
Упали на смуглую грудь,
Покрыли ей ноженьки босы,
Мешают крестьянке взглянуть.
…Красивые, ровные зубы,
Что крупные перлы, у ней,
Но строго румяные губы
Хранят их красу от людей…

**Активизация знаний по предыдущей теме**: Найдите прилагательные в отрывке. На какие вопросы они отвечают? Какую синтаксическую роль играют в данном тексте? Все ли прилагательные вы смогли ˝опознать˝? Что вызвало затруднение?

**Целеполагание** (после выполнения предыдущего задания): попробуйте сформулировать тему сегодняшнего урока (Тема: Прилагательные полные и краткие)

**Усвоение новых знаний (с помощью решения проблемной ситуации)**

На доске выписаны в два столбика в таблице слова:

| | |
|---|---|
| Румяна, стройна, высока, красива,… | Тяжелые, смуглую… |

Вопросы для эвристической беседы:

1) Выделите окончания в словах в обеих столбцах таблицы. Можно ли слова в первой колонке ˝сделать˝ такими же, как во второй? (Румяна – румяная, стройна – стройная и т.д.) Сделайте вывод: можно ли все перечисленные слова отнести к одной части речи?

Какие грамматические признаки имеют слова в первом столбце? (род и число). Напишите все возможные грамматические формы слова ˝высока˝.

В чем различие прилагательных в разных столбцах таблицы? На какие вопросы они отвечают? Как вы думаете, они являются одинаковыми членами предложения или разными? Выскажите предположения.

Давайте откроем учебник, проверим, правильны ли наши выводы. Прочтем правило из учебника [Русский язык 2012: 92].

**Первичная проверка понимания***:*

1) Озаглавьте столбцы таблицы.

2) Дополните столбцы: выпишите остальные прилагательные из стихотворного отрывка.

3) Является ли краткое прилагательное в словосочетании ˝ноженьки босы˝ сказуемым? Докажите свою точку зрения, опираясь на текст.

**Первичное закрепление**

1) Давайте попробуем определить роль прилагательных в данном поэтическом тексте. Для чего их использует автор? (в данном тексте – для описания внешности героини)

2) Каким средством выразительности являются прилагательные в словосочетаниях: ˝что крупные перлы˝, ˝румяные губы˝? Посмотрите в Толковом словаре. Ответ: сравнение, эпитет. ‘Перлы’. Жемчуг, жемчужина (устар.). Ожерелье из перлов. Перлы зубов (перен.: о белых, блестящих зубах).

Подчеркните эпитеты, те прилагательные, которые описывают существительное, допишите 1 свой подходящий по смыслу эпитет к каждому существительному из первого столбца.

Учащиеся получают листы бумаги с заполненной таблицей. Они должны за 5 минут выполнить задание.

| **Существительное** | **Прилагательное** |
|---|---|
| Лицо | прекрасное, одухотворенное, … |
| Руки | грубые, мозолистые, … |
| Волосы | русые, непослушные, … |
| Характер | открытый, деятельный, … |

**Подведение итогов урока. Рефлексия.**

Какие формы есть у прилагательных? Как они меняются? Какова их синтаксическая роль?

Приведите свои примеры полных и кратких прилагательных (по цепочке каждый ученик)

**Домашнее задание.** Выпишите краткие и полные прилагательные из 2-й части поэмы Н.А.Некрасова ˝Мороз, Красный нос˝, строфа 23.

## Литература

Богородицкий В.А. Очерки по языковедению и русскому языку: пособие при изучении науки о языке / В.А.Богородицкий. – Изд. 2, исправленное и значительно дополненное. – Казань: типография Императорского университета, 1909.

Дейкина А.Д. Аксиологическая методика преподавания русского языка: монография / А.Д.Дейкина. – Москва: МПГУ, 2019.

Кубрякова Е.С. Об установках современной науки и актуальных проблемах когнитивной лингвистики / Е.С.Кубрякова // Вопросы когнитивной лингвистики. – 2004. – №1. – С.6-17.

Русский язык. 5 класс. Учеб. для общеобразоват. учреждений в 2 ч. Ч.2 / Т.А.Ладыженская, М.Т.Баранов, Л.А.Тростенцова и др.; науч. ред. Н.М.Шанский. – М.: Просвещение, 2012.

**Миннубаева Фируза Фанисовна**
Казанский (Приволжский) федеральный университет
УДК 811

## Татар һәм чуваш халыкларында исем кушу йолалары

*йола, бала, исем кушу, татар теле, чуваш теле*

Төрки халыкларда бала туу йоласы үзенең килеп чыгышы белән кеше җаны – аның исеме, исем – язмышның алдан билгеләнү чарасы дигән карашлар һәм ышанулар системасына бәйле формалашкан. Балага исем кушу ритуалы күп кенә башка йолалар һәм гамәлләр белән үрелеп бара. Исем бирү һәм исемне үзгәртү гореф-гадәтләре борынгы төркиләрнең рун язулы Енисей кабер ташларында да теркәлгән [Малов 1951; Кляшторный 1964; Кормушин 1997].

Традицион татар һәм чуваш мәдәниятләрендә йолалар тамыр җәйгән, шул исәптән кешегә исем бирү турындагы идеяләр һәм аларны тормышка ашыру процессы да йола кагыйдәләре белән бәйле. Бу татар һәм чуваш халыкларының исемне җанның бер өлеше, ягъни исем үзгәрү белән кешенең асылы үзгәрә икәнлегенә ышануы белән бәйле. Шуңа күрә шәхси исемнәр кешене авырулардан дәвалауга яки аны кайбер начар вакыйгалардан саклауга юнәлтелгән йолалар элементлары да булырга мөмкин.

Элек-электән яңа туган балага матур, гармонияле һәм мәгънәле исем кушу ата-аналарның төп бурычларының берсе дип саналган, чөнки бу исем, күпчелек ышанулар буенча, кешедә билгеле бер сыйфатларның булуын тәэмин итә һәм хәтта аның язмышын да алдан ук билгели. Борынгы заманнардан ук татарлар, хәтта Исламга кадәрге чорда да, исемнәргә игътибарлы булганнар. Ислам динен кабул итү исем бирү йоласына үз үзгәрешләрен керткән. Татар гаиләләрендә исем бирү йоласы ислам традицияләренең уртаклыгын күрсәтә һәм җирле мәдәни үзенчәлекләрне үз эченә ала.

Исем кушу тантанасына әзерләнү – үзгә бер йола, ул әле дә күпчелек татар гаиләләрендә һәм хәтта шәһәр гаиләләрендә дә саклана. Монда әби-бабайлар аерым роль уйныйлар. Алар хуш исле үләннәрдән һәм каен яфракларыннан мунча себеркесен җыярга тиешләр. Бала юыла, бу себерке белән әкрен генә сугыла, һәм шул ук вакытта алар балага сәламәтлек һәм бәхет телиләр. Су процедураларыннан соң, балага әбисе бәйләгән оекбашларны кидерәләр. Гаиләдәге өлкән буын вәкилләре балага дип махсус мендәр әзерләгән була. Аның өстендә бала исем кушканда ята.

Хәзерге вакытта исем бирү тантанасы түбәндәге этаплардан тора.

Мулланы чакыру. Кыямәт көнендә бала Аллаһ алдында басачак исемне гадәттә мулла бирә. Шулай ук, бу процедураны әгәр дә дини белем булса, әти, бабай, яңа туган баланың абыйсы башкарырга мөмкин.

Исемләү процессы. Бала туганга җиденче көнне исем бирү оптималь санала, ләкин бу шарт мәҗбүри түгел. Бала йоклаганда да исем кушу рөхсәт ителә. Ритуал үзе түбәндәге эзлеклелектә башкарыла:

– баланы кыйблага таба боралар (баланың башы мендәргә куела, аяклары кыйблага таба сузыла һәм мулла алдында куела);

– азан укыла;

– исемне әйтү (мулла баланың уң колагына таяна һәм исемен тыныч кына өч тапкыр әйтә) [Баязитова 1992].

Шундый ышану да бар: тантана вакытында бала еласа, бу аңа исеме ошаган һәм бәхет китерәчәк дигәнне аңлаткан. Бу кычкыру белән, бала, шулай дип аталырга ризалык бирә дип ышанганнар.

Исем кушуның соңгы этабы булып “бәби туе” санала. Бу чара бәйрәм мәҗлесе булып санала. Анда ата-аналар, әби-бабайлар, гаилә әгъзалары, кендек әбиләре катнаша ала. Башта табын артына ир-ат туганнар чакырыла, берничә көннән соң – хатын-кызлар. Нәкъ менә бу этап этнографик чыганакларда иң ачык һәм җентеклэп сурәтләнә. Гомумән, уртак аш – кеше тормышындагы тагын ике туйның үзәк эпизоды

(никах һәм җеназа). Бәлки, бергә ашау, утилитар булудан тыш, тагын берничә функциягә бәйле: бу иҗтимагый элемтәләрне ныгыта, “магик консолидацияләү акты”, “югары дәрәҗәдә актуаль” һәм Аллаһка яраклы социаль бәйләнеш формасы санала.

Исем кушу көне зур гаилә бәйрәме булып санала. Баланың әти-әнисе бу бәйрәмгә мулланы, туганнарын һәм дусларын чакыра. Кайвакыт күрше авыллардан да кунаклар килгән була. Чакырылганнарның барысы да яңа туган балага бүләкләр китерәләр: ризыклар һәм киемнәр. Бүләк бирү табынга бал һәм май чыгарылганнан соң башлана. Бәйрәм табынында хәләл бәрән яки сыер итеннән пешерелгән аш һәм зур бәлеш булырга тиеш.

Безнең ата-бабалар исемсез сабый ике дөнья арасында яшәгән кебек була һәм аны шайтан алып китә ала дип ышанган. Явыз рухларның һөҗүменнән саклану өчен, бала йоклый торган мендәр астына тимер әйбер кую гадәткә кергән. Татарлар тимер баланың җанын саклар һәм аңа тыныч йокы бирер дип ышанган.

Ләкин заманалар үзгәрә. Хәзер исем кушу йоласы алай катгый үтәлми. Элегрәк ата-аналар балага күз тиюдән куркып, алдан исем бирмәскә тырышсалар, хәзер бала туганчы ук аның исеме чигелгән киемнәр дә сатып алалар.

Хәзерге вакытта тарихи тамырларга, дингә кире кайту күзәтелә, исем кушу йоласы да барлык кагыйдәләр буенча мулла һәм кунаклар чакырып, яисә яңа туган баланы мәчеткә алып барып кушыла.

Чувашлар да татар халкы кебек үк, исемгә зур әһәмият биргән, кеше язмышы аның исеменә бәйле дип ышанган. Чуваш антропонимиясендә берничә мең традицион исемнәр теркәлгән. Балага исем кушуың берничә варианты булган:

1) кендек әбисе, баланы юганда, аның колагына төрле исемнәр пышылдый; бала кайсы исемне атаганда тавыш бирсә, аңа шул исем кушылган;

2) яңа туган баланың җенесе аның әтисенә әйтелгән һәм ул урамга чыккан, кемне беренче булып очратса – шул кешенең исеме яңа туган балага кушылган;

3) балалар еш үлгән гаиләләрдә кендек әбисе баланы башта ишегалдына чыгарган, эткә баланы яларга биргән; аннары аның әти-әнисе аны тәрәзә аша “йолып алганнар”, бу балага Суппи (Чүп бөртеге), Туппи (Табылдык) һ.б. исемнәр кушылган;

4) олы туганнары белән килешеп, ата-аналар баланың исемен туганчы ук сайлаганнар.

Шул ук вакытта, малайлар өчен, үлгән ата-бабалар исемнәренә туры килгән исем өстенлек бирелгән; бу нәселгә ярдәм итә дип ышанганнар. Бу вариантларның барысы да балага исем кушу (ача яшки – баланың шулпасы) процессында расланды.

Чувашларда балага исем кушу йоласы шулай ук күп кенә ышанулар, гореф-гадәтләр белән бәйле. Бала тугач, аны тозлы су белән юганнар, баланы юындыра торган тазның төбенә тәңкә салганнар. Баланы юындырган чакта: “Бай бул, башкаларның явызлыгы сиңа кагылмасын”, дип теләгәннәр. Ахырда, кендек әбисе иреннәрен баланың аркасы буйлап, өч тапкыр йөгертергә, агып торган суны авызына алып, кире тазга түкерергә тиеш булган. Бала ата-анасының берсенең күлмәгеннән уралган. Бала эш сөючән булып үссен өчен, алар плацентаны юып, аның аяк киеменә яшергәннәр һәм җир астына яки абзарга күмгәннәр [Иванов 2000].

Яңа туган баланы беренче тапкыр бишеккә яткырганчы, тагын бер йола башкарыла. Туган әби яки башка олы туганы бала белән мичкә якынрак тора, аның мич кебек көчле һәм кайнар булуын тели, теленә май һәм бал катнашмасы сала. Бишектә матрас астына талисман итеп тимер әйбер куелган. Еш кына болар кисү һәм тешләү коралларының өлешләреннән гыйбарәт була. Мәҗүсиләр шулай ук бишеккә миләш ботагы бәйләгәннәр.

Татарларда да, чувашларда да яңа туган сабыйларга үлгән балаларның исемнәрен бирү катгый тыю астында булган.

Элеккеге заманнарда чувашларда баланың беренче туган көне алдыннан икенче туган көнен бәйрәм итү гадәте булган. Кагыйдә буларак, ул башка бәйрәмнәргә туры килгән. Бу көнне Acha chăkăt (“балалар сыры”) йоласы башкарылган. Алар өстәлгә икмәк, ачылмаган сыр куйганнар, аннары торып, дога кылганнар һәм бәйрәмдә

катнашучыларга икмәк һәм сыр таратканнар. Шул ук вакытта алар: “Бу бала ныклы булсын”, – дип, теләк теләгәннәр. Бәйрәм вакытында шулай ук бүләкләр белән алышынганнар. Чукындыручы әнкәсе балага күлмәк, әнисенә – сурпан (тукыма полосасы формасында баш киеме), ә әтисенә – күлмәк биргән.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, традицион мәдәниятләрдә исем бирү, һичшиксез, социаль статусны модельләштерүнең төп формасы булган. Характерлы, кечкенә кеше образын үз эченә алган исем аның киләчәген алдан билгели дип ышанганнар. Томск татарлары аңлатуы буенча, туганнар, исем биргәндә, баланың булачак исеме лаексыз яки ярлы күрше исеме белән туры китермәскә омтылулары очраклы түгел.

Исем алгач, бала тормышның беренче көннәреннән үк гаилә мөнәсәбәтләре системасына кертелә. Аның киләчәктә яшәвенең асылы гаилә, җәмгыять, кабилә коллективы белән әкренләп танышудан башлана.

### Әдәбият


Баязитова Ф.С. Гомернең өч туе (татар халкының гаилә йолалары) / Ф.С.Баязитова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 295 б.

Иванов В.П. Чуваши: этническая история и традиционная культура / В.П.Иванов, В.В.Николаев, В.Д.Димитриев. – М.: ДИК, 2000. – 100 с.

Кляшторный С.Г. Древнетюркские рунические памятники / С.Г.Кляшторный. – М.: Наука, 1964.

Кормушин И.В. Тюркские енисейские эпитафии. Тексты и исследования / И.В.Кормушин. – М.: Наука, 1997. – 303 с.

Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности: тексты и исследования / С.Е.Малов. – М.; Л., 1951. – 451 с.



**Мотигуллина Альфия Рухулловна**
Поволжский государственный университет
физической культуры, спорта и туризма



УДК 821.512.145


## Әдәби әсәр текстында чит сөйләм төрләрен куллану (А.Хәлимнең “Татар вакыты” романы мисалында)


*чит сөйләм, монолог, текст, пародия, сөйләк (сказ), роман*


Текст төшенчәсе лингвистикада, әдәбият белемендә, эстетикада, семиотикада, культурология һәм башка өлкәләрдә файдаланыла. Ул беренче чиратта тел белеме белән бәйле категория буларак мәгълүмат җиткерүгә корыла. Шулай да киң мәгънәсендә төрле эчтәлекле, күләмле, формалы язмаларны текст астына туплыйбыз.

Әдәби әсәр дә эзлекле, күләмле текст булып тора. Аңа салынган мәгълүмат итсә авторның күзаллавы, карашлары, сүз белән сурәт ясау осталыгына бәйле. Әдәби әсәр текстында чит сөйләм куллану проблемаларын өйрәнгән галим-тикшеренүче О.А.Блинова “В контексте репрезентации чужой речи мы имеем дело с автором, который говорит не от своего лица, а от лица персонажа, а не просто максимально верное воспроизведение действительности˝, - дип раслый [Блинова 2021: 154].

Белгәнебезчә, матур әдәбият әсәре беренче чиратта автор һәм укучының диалогын күздә тота. Әсәрдәге персонажлар үзара аралаша, бәхәсләшә. Шуңа күрә әдәби әсәргә бәя бирү барышын авторны, хәтта аның прототибы булган персонажны аерып карыйбыз. Бу очракны әдәбият белемендә чит сөйләм куллану дип атыйлар. Бу күренешне рус әдәбият галиме М.М.Бахтин “күптавышлылык”, – дип кенә калмый, ә Ф.Достоевский әсәрләренең тел үзенчәлекләрен өйрәнү барышында чит сөйләмгә нигезләнгән жанр үзенчәлекләре алмашынуны анализлый: “Резкие и неожиданные переходы от пародии к внутренней полемике, от полемики к скрытому диалогу, от скрытого диалога к стилизации успокоенных житийных тонов, от них опять к пародийному расска-

зу и, наконец, к исключительно напряжённому открытому диалогу - такова взволнованная словесная поверхность этих произведений” [Бахтин 2015: 307].

Чит сөйләмнең әдәби әсәр эчендәге вазифаларын теоретик нигездә өйрәнгән тикшеренүче Е.С.Зорина исә “Многоголосие, полимодальность повествования предполагают диалог между автором и читателем, активное участие реципиента в формировании текста. ... ˝Чужая речь˝ не только передает речь героев, это часть концептуального уровня художественного произведения” [Зорина 2011: 138]. Әдәбият теориясе белгече В.Е.Хализев әдәби әсәрдә чит сөйләмнең стиль саклау (стилизация), пародия, сказ (сөйләк) дигән төрләрен аерып карый [Хализев 2000: 250-252].

Шушы теоретик эзләнүләргә һәм ачыш-табышларга нигезләнеп, әдәби әсәрдә чит сөйләм формасын өйрәнү өчен Айдар Хәлимнең “Татар вакыты” (1998) романын сайладык. Әсәргә беренчеләрдән булып бәя бирүче Ә.Дусайлы анда күтәрелгән проблемаларны ачыклап: “Татар вакыты”нда төп проблеманы аерып алуы авыр. ... Монда тел мәсьәләсе дә, милли гореф-гадәтләр дә, сугыш һәм аңа шактый ориганаль караш мәсьәләләре дә бар”, - дип белдерә [Дусайлы 2002: 361]. Әсәрдә татар халкының язмышы, теле, мәдәнияты саклану мәсьәләләре үзәккә куела. Әлеге проблемаларны автор төп герой Мотаһар карт Чанборисов аша ачарга омтыла.Ул Бөек Ватан сугышы инвалиды, бихисап орден-медальләр кавалеры.Казанда гомер кичергән, хәзерге вакытта улы Мөдәррис, килене һәм оныгы Вадик белән яши.

Мотаһар картның бер җитешсезлеге бар – ул сукыр. Аның тирә-юньне иңләү мөмкинлеге чикле булуын ассызыклап, автор герое яшәгән пространствоның тараюын күрсәтә: ул фатир диварлары эченә бикләнгән, кайбер вакытта гына урамга чыга. Мотаһар картны даими кызыксындырып торган әйбер – вакыт. Шуңа күрә автор аны әсәр исеменә дә чыгарган, роман кысаларында да шул юнәлештә ачыла. Радиодан вакытны тыңлый, япон сәгате вакытны әйтә, әмма стенадагы күкеле сәгатьне генә туктатып куялар. Геройнысәгать санаудан мәхрүм итеп, татар халкының яшәеше, үткәне һәм киләчәге белән бәйле вакыйгалардан ерагайтып куялар.

Романдагы бүгенге вакыт ул тормыш та, гаилә эчендәге һәм җәмгыятьтәге проблемалар да булып күзаллана. Вакыт белән бүгенге көндә гаилә эчендәге проблеманың иң әһәмиятлесе - туган телне саклап калу тыгыз бәйләнгән. Мотаһар картның бу проблеманы чишү юлларын автор чит сөйләмгә нигезләнеп ача. Аны автор персонажлар арасындагы диалоглар ашабирә. Мотаһарның даими аралашып торган кешесе килене Зөмәрә. Гаиләгә килеп кергәндә аны татар кызы, исеме дә татарча дип кабул итәләр.”Мөдәррисе (улы Ә.М.) өйгә марҗа китереп, канны бозмады. Татар кызына – Бондюг кызына өйләнде. Әй, куандылар ул чакта Мотаһар белән Зөлхәбирә!” [Хәлим 2002: 299]. Әмма тормышта килен бөтенләй башка яктан ачыла. Автор бу образны ачуда тел-сөйләм чараларыннан урынлы файлана. Мотаһар белән киленеарасындагы аралашуны автор түбәндәгечә җиткерә:

“– Чәй агызыйммы” (Зөмәрә)

Әйе, “ясыйммы?” димәде ул, “агызыйммы?” диде. (Мотаһар) [Хәлим 2002: 298].

Чит сөйләм чараларын автор кайбер очракта диалоглар аша, ә кайбер урыннарда Мотаһар картның монологы рәвешендә кертеп җибәрә: “Аңламый Мотаһар: мәктәп кадәр мәктәптә, татарча белмәгән адәм татар сәнгате турында ничек сабак бирә икән? Урыс теләндә түгелдер бит инде?! Җитмәсә Казанда! Киленнең аңа бервакытта да авыз тутырып, “Әти!”, йә булмаса, “Папа!” дип тә эндәшкәне юк. Ул аңа чүплектә үскән күплектә генә мөрәҗәгать итә: “Идите кушать” [Хәлим 2002: 299]. Шул рәвешле, А.Хәлим әлеге монологы телне белмәүче татарларга пародия булып яңгырый.

Тел мәсьәләсендә автор телне бозып сөйләшүче руслашкан татар кешеләренең сөйләменә игътибар юнәлтә. Романда сугыш бетеп, илле дүрт ел узгач, Мотаһар Чанборисовның сугышта алган бүләкләрен тапшыру комиссиясе килә.Хәрби комиссариаттан килгән Ярмухаметов, аның белән килгән Сәкинә Хисамовна Чернобровкинаның сөйләме татар телен бозып сөйләшүгә пародия булып тора: “Гафью итегез, мин татарча начар суляшам, - позвольте местами урысча говорить. ... Комиссариатта офицеров мало, хезмәт хакы түләнми, короче. Әгәр сезнин фамилия “А”дан башланган булса, иртяряк та

пришли бы.Ә сезники “Ч”! Замыкающий. … Хярби хезмятта, билясез, ранжир, субординация, алфавит!... [Хәлим 2002: 338]. Шул рәвешле, автор төрле катлам кешеләренең сөйләм үзенчәлекләрен әсәр кысасында биреп, телнең бозылуына, “ярлылануына” китергән сәбәпләрне эзли, персонаж сөйләме аша үз мөнәсәбәтен белдерә, татар халкының милли-мәдәни кыйбласы югала баруына борчыла.

Шулай да А.Хәлим героеның тел сагында торуын, үз нәселенең үткәнен онытмавын аерым ассызыклап куя.

Мотаһар үз нәселенең тарихын монолог-искә төшерү аша җитерә: “...Әтисе Хафиз Казанның черегән бае булмаса да, төшеп калганнардан да түгел иде. “Онытмагыз, без атаклы Җан Барыс нәселеннән!” – дип күкрәк кагарга ярата иде әтисе кәефле чакларында. – Җаны Барыска “оф” өстәп, аны урыс кына имгәтте” [Хәлим 2002: 307-308]. Шул рәвешле, Мотаһар нәселенең данлы үткәнен дә барлый, үзе үткән юлны да сөйләп ала. Туксанынчы елларда барган һәр яңалыкны, күзе сукыр булса да,ишетеп тә, бәяләп тә бара. Үзгәртеп кору чорындагы урам исемнәре алмаштыру, илдәге яңалыклар барысы да Мотаһар карашлары аша бирелә.

Романдагы чор картинасын тудыру эше тулаем Мотаһар картка йөкләнә. Аның үткән юлы, башыннан кичкән вакыйгалар белән таныштырып, тасвирлап бару барышында автор пародиягә мөрәҗәгать итә. Бу як төп геройның илдәге сәясәткә бәя бирүе буларак ачыла. Кайчандыр партиягә керүдән баш тарта. Ә хәзер исә “бүгенге дөмкрат дигәннәре, көне-төне ниткәндер сәтсиәл гаделлек турында чүбек чәйни - ә яшисе килми. Чүбек чәйниләр дә атышалар, чүбек чәйниләр дә үтерешәләр “[Хәлим 2002: 300].

Картның гаилә тормышын да автор героеннан сөйләтә: “Моннан биш ел элек берсе тома сукыр, икенчесе чатан һәм кулсыз карт белән карчык, нокталы өтер кебек култыклашып, мунчага барган иделәр. Әмма карт, бу каһәрле мунчадан өтерен югалтып, ялгыз нокта булып кайтты. Дәресрәге, мунчаның йөк машинасы китереп куйды аларны. Машина әрҗәсендә Зөлхәбирәнең өстенә ак тукыма ябылган гәүдәсе иде “[Хәлим 2002: 302]. Күрәбез, чит сөйләм аша тормыштагы иң зур югалту да көлү алымнары аша ачыла. А.Хәлим татар теленең лексик (каламбур, плеаназм һ.б.), семантик, телстильчараларының мөмкинлекләрен киң файдаланып, телнең матурлыгын, сыгылмалылыгын күрсәткән роман иҗат итә.

Шул рәвешле, А.Хәлимнең “Татар вакыты” романы текстында чит сөйләм куллану үзенчәлекләрен өйрәнеп, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Автор чит сөйләм куллануда персонажлар арасындагы монолог, диалог, полилогларны уңышлы файдалана.
2. Чит сөйләмнең әдәби тексттан тыш элементы буларак стилизация урынлы кертеп җибәрелә.
3. Телне саклау, илдәге кайбер үзгәрешләрне тасвирлау өчен пародияләргә мөрәҗәгать итә.
4. Татар теленең әдәби тел нормаларын сакламау, сөйләм телен бозып сөйләшүчит сөйләмнең сөйләк (сказ) формасы аша бирелә.

**Әдәбият**


Бахтин М.М. Проблемы поэтики Достоевского / М.М.Бахтин. – СПб.: Азбука-Аттикус, 2015. – 412 с.

Блинова О.А. Способы передачи чужой речи в художественном тексте (миметическая классификация) / О.А.Блинова // Russian Linguistic Bulletin. – № 4 (28). – 2021. – С.153-157.

Дусайлы Ә. Айдар Хәлим прозасы / Ә.Дусайлы // Айдар Хәлим. Татар моңы. Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар кит. нәшр., 2002. – Б. 359-382.

Зорина Е.С. ˝Чужая речь˝ и речь автора в современном художественном тексте / Е.С.Зорина // Вестник Санкт-Петербургского университета. Язык и литература. – 2011. – С.134-139.

Хализев В.Е. Теория литературы / В.Е.Хализев. – М.: Высш. шк., 2000. – 398 с.

Хәлим Айдар. Татар вакыты // Айдар Хәлим. Татар моңы. Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар кит. нәшр., 2002. – Б.295-358.

**Мугтасимова Гульназ Ринатовна**
**Фатхуллова Кадрия Сунгатовна**
Казанский (Приволжский) федеральный университет
УДК 81.272

## Татар теле дәресләрендә тыңлап аңлауга өйрәтү вакытындагы кыенлыкларны җиңү ысуллары

*татар теле, тыңлап аңлау, тыңлап аңлауга өйрәтү, тыңлап аңлау вакытындагы кыенлыклар*

Соңгы елларда тыңлап аңлау проблемасы психологларның, психолингвистларның һәм методистларның игътибарын җәлеп итә. Әлеге катлаулы процессның теоретик закончалыклары һәм үзенчәлекләре тикшерелә. Әмма хәзерге вакытка кадәр күп проблемалар ахыргача хәл ителмәгән булып кала бирә.

Иң элек, тыңлап аңлау төшенчәсенең мәгънәсен билгелик. Билгеле булганча, тыңлап аңлау ул – сөйләшүнең аерылгысыз бер өлеше. Әмма урта мәктәптә һәм югары уку йортларында татар телен өйрәтү тәҗрибәсе күрсәткәнчә, уку, язуга игътибар җитәрлек булса да, тыңлап аңлауга игътибар бик аз. Югыйсә тыңлап аңлау мөстәкыйль, кирәкле һәм укучылар өчен иң авыр сөйләм эшчәнлеге төре булып тора.

Дәрестә бары тик сөйләм яки тел күнекмәсен генә формалаштыру мөмкин түгел. Аудио һәм видеоматериал белән эшләгәндә, лексик, грамматик, фонетик күнекмәләр бер үк вакытта үзләштерелә. Аудио һәм видеоматериаллар фикер алышу өчен мәгълүмат бирә. Бу исә, үз чиратында, сөйләм яки язу күнекмәләрен камилләштерүне дә күздә тота. Тыңлап аңлау да, уку да мәгълүматны кабул итүгә һәм мәгънәви эшкәртүгә юнәлдерелгән. Сөйләм эшчәнлегенең рецептив төрләрен тәшкил итә торган сөйләм механизмнарының уртаклыгы шуның белән аңлатыла. Тыңлап аңлау һәм сөйләшү телдән сөйләм дип аталган күренешнең ике ягын тәшкил итә. Аралашу тыңлап аңлауга ия булудан башлана.

Студентларны татар теленә өйрәтү тәҗрибәсе тыңлап аңлауның сөйләм эшчәнлегенең иң катлаулы төрләреннән берсе булуын раслый. Укучыларга татарча әйтелгәннәрне игътибар белән тыңлауның, ишеткәннәренең конкрет ситуациягә бәйләнешен, әлеге ситуацияне күз алдына китерүнең никадәр мөһим булуын аңлату уңышлы. Г.В. Рогова һәм И.Н. Верещагина тыңлый белү сәләте, тел өйрәнгәндә, уңыш нигезе булуын искәртә. Укытучының укучыларда үздисциплина формалаштыру, тәрбияләүгә өндәгән махсус күрсәтмәләре, мәсәлән, укытучыны, иптәшеңне, дикторны игътибар белән тыңлый белү; үзләштерелә торган сөйләмне хәтереңдә саклап калырга тырышу һ.б. ярдәмендә моңа ирешеп була [Рогова 1988: 121].

Е.Н. Соловова фикеренчә, хәбәрнең эчтәлеген аңлауга комачаулый торган 3 төрле кыенлык бар: тыңлап аңлау шартлары белән бәйле кыенлыклар; сөйләм чыганагының шәхси үзенчәлекләренә бәйле кыенлыклар; кабул ителә торган материалның тел үзенчәлекләре белән бәйле кыенлыклар: таныш булмаган лексика, фразеологизмнар, терминнар, кыскартылма сүзләр һәм башкалар кулланылу [Соловова 2006: 125-127]. Методикада кыенлыклар белән көрәшүнең ике юлы бар: 1) аларны булдырмау яисә 2) аларны җиңү. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: тыңлап аңлау вакытында кыенлыкларны ясалма рәвештә булдырмау аутентик, ягъни табигый сөйләмне кабул итүгә әзерләми.

Теоретик материалны өйрәнеп, татар теле дәресләрендә тыңлап аңлау вакытындагы кыенлыкларны җиңүгә юнәлдерелгән ысулларны барларга тырыштык.

Казан федераль университетының рус телле һәм чит ил студентларын аралашу чарасы буларак татар теленә өйрәтү өчен, ˝Татарча сөйләшик˝ дәреслеге тәкъдим

ителә [Фатхуллова 2022: 312]. Шунысы мөһим, әлеге дәреслекнең тыңлап аңлау буенча биремнәрен QR-код аша кереп тыңларга мөмкин. Бу татар телен элементар дәрәҗәдән өйрәнүчеләр өчен өстәмә мөмкинлекләр тудыра. Күпчелек төркемнәрдә студентларның татар телен белү дәрәҗәсе нык аерыла. Бу фактны дәрескә өстәмә аудио һәм видеоматериал сайлаганда исәпкә алырга туры килә.

Телгә өйрәтүнең төп максаты – укучыны табигый шартларда аралашуга әзерләү, шуңа күрә студент аутентик сөйләм кыенлыклары белән очрашып, аларны җиңәргә өйрәнсә генә, белем бирү процессы нәтиҗәле булачагын да искәртик.

Моннан тыш, ФГОС таләпләренең берсе – социальләшү, шуңа күрә тыңлап аңлау өчен иң яхшысы – тормышка бик якын булган аутентик материалларны сайлау.

Тыңлау өчен сайлап алына торган материаллар кызыклы һәм мәгълүматлы яки фаразлауга этәргеч булырга тиеш. Тыңлап аңлауны камилләштерү өчен, шактый авыр күнегүләр эшләү нәтиҗәле булачак, дип саныйбыз, әмма бу кыенлыкларны җиңәргә студентларның көче җитәрлек булу – шарт.

Хәбәрне тыңлау шартлары белән бәйле кыенлыкларга аның бер тапкыр гына әйтелүен, шулай ук сөйләм темпын күздә тотып, кыска вакытлы булуын кертергә мөмкин. Чынбарлыкта, кагыйдә буларак, хәбәр бер тапкыр гына әйтелә. Тыңлап аңлауның иң мөһим максатларының берсе – укучыны чынбарлыктагы табигый шартларда хәбәрләрне аңларга өйрәтүне нигез итеп алсак, аудио һәм видеоматериалларны бер генә тапкыр тыңлауның мәгънәсе бар. Шуңа да карамастан, материалны кабат тыңлау, һичшиксез, аңларга ярдәм итә һәм татарча тыңлап аңлауга өйрәтүдә без бу ысулны да кулланабыз.

Хәбәрне яхшырак аңлау һәм истә калдыру өчен, аның әйтелеш темпын дөрес сайларга кирәк. Чынбарлыкта студентларга хәтта бер үк кешенең сөйләм темпы шактый үзгәреп торуы белән очрашырга туры киләчәк. Ул сөйләүченең кәефенә дә бәйле бит әле. Шуңа күрә студентларны тыңлап аңлауга өйрәткәндә, төрле эмоциональ төсмердәге татарча аудио һәм видеоматериалларны куллану максатка ярашлы дип саныйбыз.

Методикада тыңлап аңлау проблемаларын бетерүгә юнәлдерелгән күнегүләр системасы бар. Мәсәлән, хәбәрне тыңлау шартлары белән бәйле кыенлыкларны бетерү өчен, түбәндәге күнегүләрне эшләргә була:

1) Түбәндәге сүзләрне тыңлагыз һәм, [ә] авазы булган сүзне ишеткәч, кулыгызны күтәрегез.

2) Җөмләләрне тыңлагыз һәм, сорау җөмләне ишеткәч, кулыгызны күтәрегез.

3) Татарча сүзләр исемлегендә ишеткән сүзләрнең астына сызыгыз һ.б.

Хәбәрнең тел үзенчәлекләре белән бәйле кыенлыкларны фонетик һәм лексик төрләргә аерып карарга була. Башлангыч чор өчен төп фонетик кыенлыкларның берсе – сүзләр арасында төгәл чикләрне тоймау. Фонетик кыенлыклар арасында ике сүз арасында килгән сузыкларның үзгәреше һәм редукция дә бар. Шушы үзенчәлекләр аркасында, беренче карашка гади һәм таныш сүзләр, сүзтезмәләр тәүге тапкыр ишеткәндәге кебек кабул ителергә мөмкин.

Хәбәрнең гомуми мәгънәсен аңлауны кыенлаштыра торган таныш булмаган сүзләрнең артык булуы лексик кыенлыкларны тәшкил итә. Лексик кыенлыкларны уңышлы хәл итү өчен, бер яктан, студентларны аеруча еш очрый торган фразеологизм, клише, сөйләм модельләренә һәм аларны куллану ситуацияләренә өйрәтергә кирәк. Икенче яктан, студентларның тел белү дәрәҗәсенә туры килгән лексик материлны дөрес итеп сайлауга аерым игътибар бирү сорала.

Аудиоматериалның чыганагы – тавыш. Практика күрсәткәнчә, студентларның төрледән-төрле тавышларны – ирләр, хатын-кызлар, балалар, шулай ук өлкән яшьтәге кешеләрнең тавышларын тыңларга мөмкинлекләре булырга тиеш. Артикуляциянең яшь үзенчәлекләренә бәйле балалар һәм өлкән яшьтәге кешеләрнең тавышларын тыңлап аңлау аеруча кыенлык тудыра.

Шулай итеп, тыңлап аңлауга өйрәткәндә, татар теле укытучысы тиешле материалны бик җентекләп сайлап алырга, шулай ук сөйләм эшчәнлегенең әлеге төренә

караган үзенчәлекләргә бәйле барлык кыенлыкларны да аңлап һәм исәпкә алып эш итәргә тиешлеген тагын бер кат билгеләп үтәсебез килә. Тыңлап аңлау – студентларның грамоталы аралаша белү сәләтен формалаштыруга ярдәм итә торган сөйләм эшчәнлеге.

**Әдәбият**

Рогова Г.В. Методика обучения английскому языку на начальном этапе в средней школе: пособие для учителя / Г.В.Рогова, И.Н.Верещагина. – М.: Просвещение, 1988. – 224 с.

Соловова Е.Н. Методика обучения иностранным языкам: базовый курс / Е.Н.Соловова. – М: АСТ: Астрель, 2006. – 238 с.

Фатхуллова К.С. Давайте говорить по-татарски: учебное пособие для русскоязычных студентов / К.С.Фатхуллова, А.Ш.Юсупова, Э.Н.Денмухаметова. – Казань: Тат.кн.изд., 2022. – 312 с.

**Мулласалихова Гульсира Гусмановна**
Шеморданский лицей ˝Рост˝
Сабинского муниципального района Республики Татарстан
УДК 81`33

## Фразеологизмнар – телнең җәүһәрләре

*фразеологизмы, калька, фразеологические синонимы, семантика фразеологизмов*

Фразеологизмнар безнең телебезгә ˝бизәк˝ өстиләр, алар сөйләмне образлы итә. Фразеологик әйтелмәләрне телнең җәүһәрләре дип йөртәләр. Аларда икедән алып җиде-сигезгә хәтле сүз була: *агач авыз — мямля; авызы колакка җитү — рот до ушей; баш белән җавап бирү – отвечать головой; чыпчык дулап, киртә җимерә алмый – буря в стакане воды; ни он түгел, ни камыр түгел – ни рыба, ни мясо; авызың тулы кара кан булса да, дошман алдында түкермәү – делать хорошую мину при плохой игре.*

Татар телендә фразеологизмнар тиешенчә өйрәнелгән дип уйларга җирлек бар.

1957 нче елда ˝Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре˝ дигән китап дөнья күрә. Төрки тел белемендә беренче булып ˝Русча –татарча фразеологик сүзлек˝ 1959 нчы елда чыга. 1982 нче елда Г.Х.Әхәтовның ˝Татар теленең әйтелмәләр сүзлеге˝ басылган. Ә 1989-1990 нчы елларда ике томда ˝Татар теленең фразеологик сүзлеге˝ чыга. Аны халык язучысы һәм галим Нәкый Исәнбәт төзегән. Укучылар өчен Л.К.Бәйрәмова төзегән ˝Учебный тематический русско-татарский фразеологический словарь˝ бар.

Безнең республикада төрле милләт вәкилләре яшәгәнлектән, без күчерелмә мәгънәдәге сүзтезмәләрнең тәрҗемәсен дә карыйбыз: махнуть рукой – кул селтәү, находить общий язык – уртак тел табу, глаза на лоб лезут – уртак тел табу, кеше кубызына бию – плясать под чужую дудку. [Исәнбәт 1990, 4: 108,139, 182, 184, 366].

Татар телендә ˝авыз˝ сүзе белән бик күп фразеологизмнар бар: *авыз ачу, авыз ачып йөрү, авыз ачып тыңлау, авыз ачып тору, авыз белән кош тоту, авыз да ачмау, авыз да ачтырмау, авыз икмәккә тию, авыз итү, авыз йому, авыз кибү, авыз колакка кадәр җитү, авыз күтәреп йөрү, авыз пешү, авыз пычрату, авыз салындыру, авыз сулары килү, авыз тидерү, авыз турсайту, авыз тәме, авыз эчендә ботка пешерү, авыз чылату, авызга карату, авызга ни килсә, шуны сөйләү.*

Баш сүзе белән *баш бала, баш вату, баш ию, баш салу, баш югалту, башны түбән салу, башта җил уйнау, баш белән уйлау, баш бетү, башы ике булса, баш күтәрү, баш очында, баш әйләнү, башы яшь* фразеологик әйтелмәләре ясалган.

Телебездә ике саны кергән фразеологизмнар да бик күп: *ике атлап, бер сикерергә – одна нога здесь, другая – там; ике аякның берсен дә атламаска – ноги(моей) не*

*будет; ике куллап – обеими руками; ике кулсыз итәргә – оставить без рук; ике куян артыннан куу -– гнаться за двумя зайцами; ике күзе дүрт булу – глаза на лоб полезли; ике сыңар бер кием –два сапога пара; ике сүз белән – в двух словах; ике сүзнең берендә – то и дело; ике тамчы су кебек – как две капли воды; ике ут арасында – меж двух огней.*

Татар телендә *кот очу, кот чыгу, кот бетү, кот калмау, кот китү, котын алу, кот куну* дигән фразеологизмнар куркуны белдерә. Кот сүзе хәзер татар телендә бу мәгънәдә аерым кулланылмый. Борынгы төрки телдә ул җан, бәхет мәгънәләрен белдергән. [Ахунзянов 1963: 68].

Бәхетле, уңыш казанган кеше турында төрки телләрдә *ишәк төчкергәндә туган (родился, когда чихнул ишак),* рус телендә *родился в рубашке*, инглиз телендә – *родился с серебряной ложкой во рту, француз телендә – родился причесанным*, диләр. [Ахунҗанов 1982, 2: 47].

Телебездә фразеологик синонимнар бар. Стилистик синонимнардан төрле стилистик өлкәләргә карый торган синоним фразеологизмнар барлыкка килә. Мәсәлән, *инәдән дөя ясау-– чебеннән фил ясау; мәдхия уку -– дан җырлау;әбҗәтен әйттерү– арт сабагын укыту; авыз йому – тел тыю; кызыл кар яугач– абага чәчәк аткач; кире кагу – баш тарту һ.б.* Шулай ук *бүгенге көн белән яшәү – хәзерге көн белән яшәү, тере мәет – җанлы мәет, адәм көлкесе – кеше көлкесе, авыз ачып калырга – авыз күтәреп калырга, акылга килергә – акылга утырырга, бер түбә астында* синонимик вариантлары да кулланыла.

Семантик-стилистик синонимнарның эчке формалары үзгә, ә мәгънәләре бердәй: *үз туксаны туксан -– үз сиксәне сиксән-– үз кырыгы кырык – үз биш тиене биш тиен; үзәккә үтү– теңкәгә тию-йөрәккә төшү– тәкатьне алу – кан корыту – җелек киптерү– җан кыйнау –ярага тоз салу. Абсолют синонимнарның стилистик төсмерләре охшаш була: утсыз төтен чыкмый– җилсез яфрак селкенми, ике куян артыннан куу – ике көймә койрыгын тотарга теләү, аналары бер кояшта киптергән – капка баганалары бертуган.* Тел белемендә синонимик вариантлар күп. Алар бер-берләреннән лексик, грамматик, лексик-грамматик, фонетик, лексик-фонетик яктан аерылып торалар: *арка кашу– җилкә кашу, таш йөрәк– таш күңел, тамактан үтмәү– тамакка үтмәү, авызга тел сыймау– теле авызга сыймау, диннән язу– деннән язу һ.б.*

Капма -каршы мәгънәле фразеологизмнар да бар: *бер аягын алганчы, икенчесен эт ашый – утка баскан кебек йөри; ачык йөзле – караңгы чырайлы; шатлыктан исергән – хәсрәткә баткан; җиңел сөякле – авыр сөякле; куян җанлы – куш йөрәкле.*

Татар телендәге кебек, рус телендә дә җиде саны кергән фразеологизмнар бар: *на семи ветрах, семеро одного не ждут, на седьмом небе, семь пятниц на неделе, за семью печатьями,семь бед – один ответ* [Ахунҗанов 1982, 2: 87]

Фразеологизмнар үзгәртеп һәм үзгәртелмичә кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, Г.Кандалый *аты-чабы чыгу* тезмәсен чабы китте, чабы тулды, чабы алды кебек формаларда кулланган. Г.Тукай “Сорыкортларга” шигырендә “Чебен җанымны чын юлда бирәм бер кәррә, кызганмыйм” дип язып, яңа фразеологизм иҗат иткән.

М.Мәһдиев үзенең әсәрләрендә фразеологизмнарны мул кулланган: 1) Ике малай яз көне бүре оясының *эзенә төшкәннәр*. 2) Капчык *күз ачып йомганчы* арбада була. 3) Гыйззәтуллинның андый вакытларда *башы әйләнеп китә* дә гел киресен эшли. 4)Әлтәфинең *башы күккә тиде*.5) Ул, кызларны куып җитеп, бөтен кеше барында *шәрран ярды*. 6) Әлтафи кайткач, Зарифуллинны *эт итеп* бер сүгәрмен дип уйлады. 7) Зарифуллин *кешелектән чыкты*. 8) Моның бер *очы чыгарга тиеш* иде. 9) Ул тәмам *чыгырдан чыкты*. 10) *Бәхетең бер йомарланмасын*...Аннары бетте диген. 11) Абдуллинның *авызы ерыла*. 12) Ул авылны *күз алдына китерде* һ.б.

**Әдәбият**

Ахунзянов Э.М. Русские кальки в татарском литературном языке / Э.М.Ахунзянов // Вопросы татарского языкознания. Кн. II. – Казань: Изд-во Казан ун-та, 1963.

Ахунҗанов Г.Х.Татар теленең идиомалары / Г.Х.Ахунҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972.

Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге / Г.Х. Әхәтов. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1982.

Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. II к. / Н.Исәнбәт. – Казан, 1989, 1990.

Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. 1 том / М.Мәһдиев. – Казан: Татарстан кит. нәшр., 1995.

Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. 2 том / М.Мәһдиев. – Казан: Татарстан кит. нәшр.,1995.

Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. 3 том / М.Мәһдиев. – Казан: Татарстан кит. нәшр., 1997.

**Мухаметшина Алиса Фаизовна**
Казанский (Приволжский) федеральный университет
УДК 811.581.11, 811.512.1

## Мәдәниятләр диалогы чагылышы буларак милли ризыклар (кытай һәм төрки халыклар мисалында)

*милли ризыклар, төрки халыклар аш-суы, кытай ризыклары*

Җир шарында никадәр милләт булса, гореф-гадәтләр саны да шулкадәр. Бу гадәти күренеш, чөнки һәр халык дөньяның кайсы почмагында булуына карамастан, үз кануннары, үз йолалары, үз тәртипләре белән яши. Әлеге үзенчәлек аш-су өлкәсенә дә карый. Милләтләрнең, халыкларның үзенә генә хас ризыклары, аларны әзерләү рәвеше бар [Марушкина 2014: 3].

Пешерү ысуллары күбесенчә халыкның гореф-гадәтләре, көнкүреше, йолалары белән бәйле. Еш кына тышкы кыяфәте яки тәме белән охшаш ризыклар төрлечә әзерләнә, төрле исем белән атала, ә атамалар бер булганнары – төрле тәмдә булырга мөмкин. Алар кулланылган тәмләткечләр, ит төрләре, башка продуктлары белән дә аерылып тора.

Кытайлар белән төрки халыклар күп яктан бер-берсенә туры килеп бетми. Алар, гомумән, төрле территорияләрдә урнашкан, төрле дин, төрле тел гаиләләренә карыйлар, аларны төрле сәяси режим, төрле мәдәният, дөньяга төрле караш аерып тора. Әмма шуңа карамастан төрки телләрдә күп кенә кытай алынмалары очрый.

Бу мәкаләдә ризык төркеменә игътибар итү максаты куелды. Бу мәсьәләгә мөнәсәбәт тә әлеге халыкларда охшаш. Төрки халыкларда якыннардан хәлләрен, сәламәтлекләрен сораган вакытта, “Ашадыгызмы әле?” яки “Син бүген ашадыңмы?” дип сорыйбыз. Кытайларның исә инде хәлләрне сорау конструкциясендә үк “ашау” сүзе бар: **“你吃**饭了吗**?”** *(Син ашадыңмы? пьинин -Nǐ chīfàn le ma?*) Сораудан тыш ризыкны калдыруга караш та бер. Төрки халыкларда да, кытайларда да аш-суны кадерләргә кирәк, калдырырга ярамый һәм ашап бетерәсе дигән ышану яшәп килә.

Ризыкларның үзенә килгәндә, бу мәдәниятләрдә охшаш атамалы, охшаш кыяфәтле яки охшаш тәмле булган үрнәкләр еш очрый. Мәсәлән, Таҗикстан, Казахстан, Үзбәкстан, Башкортостан, Татарстанда пешерелә торган “манты” Кытай халкының 馒头 га *(пьинин – mántou)* тиң. Бу очракта без моны бертөрле әйтелешле булган ризык итеп кенә түгел, ә кыяфәте, әзерләү ысулы да үзара охшаш булуны күз алдында тотабыз. Кытай теленнән тәрҗемә иткәндә, 馒头 сүзе *“тутырмалы баш”* дигәнне аңлата, ягъни “эчендә нинди дә булса тутырма булган баш формасында ясалган ризык”. Төрки

халыкларда да, Кытайда да аларның формасы бер, икесе дә парда пешерелә, әмма эчлеге белән аз гына аерыла. Безнең халыкларда – ит һәм бәрәңгедән булса, кытайларда ул баллы эчлек (персик, кабак, сакура һәм роза кайнатмасы һ.б.) белән дә, тозлы эчлеК (гөмбә, доуфу, кәбестә) белән дә әзерләнергә мөмкин, ә ит һәм бәрәңге беркайчан да кулланылмый. Кытай халкында ит белән бәрәңге гомумән сирәк очрый торган кушылма.

Шулай ук бу халыкларда формасы һәм кулланылышы белән охшаш тагын бер ризык – ул чәк-чәк. Бигрәк тә татарларда һәм башкортларда очрый торган әлеге ризык майда пешерелгән вак камыр кисәкләрен суынгач бал белән катырып ясала. Татар халкындагы бу ризыкның исеменә бәйле берничә аңлатма бар. Беренчесе чык формасына охшаганлыктан, халыкта чәк-чәк дип киткән дип фаразлый. Икенчесе әлеге камыр кисәкләрен майда пешергәндә чыгарган тавыш кебек дип аңлата, өченчесе исә "чәк" сүзе "вак" мәгънәсендә килә ди. Кытай телендә аның исеме – **油条***(пьинин – yóutiáo)*. Сүзнең өлешләрен аерым алып тәрҗемә иткәндә 油 *"май"* һәм 条 *"озынча предмет",* ягъни "майлы озынча предмет" дигәнне аңлата. **油条**шулай ук майда пешерелгән озынчарак формада, ләкин зур булмаган камыр кисәкләре. Ул сап-сары төстә булганчы кыздырыла. Әлбәттә, бу территориядә бал юк, шуңа күрә дә катырылмый, ә аерым ашала. Күп очракта аны төрле тәмләткечләр ярдәмендә балландыралар, әмма тозлы варианты да еш очрый. **油条** да, чәк-чәк тә чәй эчкәндә десерт буларак тәкъдим ителә.

В настоящее время в разговорной речи татарской молодежи заимствованные слова из русского языка употребляются по нормам русского литературного языка. Например: *Апаем / Әү / Королевская ватрушканың* ***[рэ¯цэптын]*** *өйрәт әле миңа. Кичә пешергәнне / Син аны белмисең меней? / Кайчандыр пешергән бар ие инде аны әней белән, болай, аерым юк. Казанда пешерәсе ие кызлар белән / Әәә, тәмле килеп чыга шул ул, әйе. Ней, нәрсәле. Баштааа. Иң беренче инде / Аңа маргарин кирәкме? / Маргарин да ярый, сыер мае да ярый. Аннары соң аласың он, икесен бергә уасың инде. Он* ***[фōрмасына]*** *китерәсең инде. Шуннан соң* ***[твōрыг]*** *инде,* ***[твōрыгка]*** *күкәй сытасың,* ***[пэсōк]*** *саласың. Мин ванилин да салам инде булса* (Инф-ты две девушки, 19 л., студентка и 29 л. продавец).

Еще один пример: *Ни, Илдар абый, хә сез сөт-каймак сатасыз. Сез хәзер само ни, ничек атала әле ул, ә?* ***[Бизнэсмэ¯н]***, *короче. Самообеспечивающий* ***[бизнесмэ¯н]*** *булып саналасыз хә. Налог. Шундыйларга хә налог чыгардылар. Әнә* ***[рэ¯пэтитрлар]*** *бармы, теге / Ммм / Самообеспечивать итәсең үз-үзеңне. Шуның өчен син дәүләткә хә* ***[налōг]*** *түләргә тиешсең. Минә бер бабаң утыра анда* ***[карзин]*** *үрә инде, үзе пенсиядә. Аңарга хә налог түләргә тиеш, дәүләткә хә, за то, что ул самообеспечивание белән заниматься итә, дәүләт* ***[эканōмикасына]*** *акча җитми, имеш. Или минә торт пешереп саталар ич әле кайсыбер нидә, минә шундыйлардан* ***[налōг]*** *алмакчы булалар (Инф-ты муж. 29 л, муж. 22 г.).*

Таким образом, наши исследования подверждают мнение М.Р.Сайхунова о том, что ˝звуковая система татарского языка не располагает открытыми гласными, характерными для русского языка˝ [Сайхунов 2010: 12], вследствие чего произношение в заимствованных словах гласных звуков русского языка подчиняется законам татарской орфоэпии. Это явление также служит подверждением научных изысканий В.А. Богородицкого о психологии речи.

**Литература**


Богородицкий В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками / В.А.Богородицкий; под ред. Н.К.Дмитриева . – 2-е изд. испр. и доп. – Казань: Татгосиздат, 1953. – 220 с.

Бодуэн де Куртенэ И.А. Избранные труды по общему языкознанию: [в 2 т.] / И.А.Бодуэн де Куртенэ. – М.: Изд-во Акад. наук СССР, 1963. – 1963. – Т.2. – 391 с.

Сайхунов М.Р. Ритмо-темпоральные характеристики татарского языка в плане автоматического синтеза в речи: автореф. дис. канд. фил. наук / М.Р.Сайхунов. – Казань, 2010. – 26 с.

**Хан Сывэнь**
**Файзуллина Найля Ивановна**
Казанский (Приволжский) федеральный университет
УДК 811.111-26

## Текст и дискурс как вопрос современной лингвистики

*текст, дискурс, язык, понятие, анализ, аспект*

Одним из неоднозначных вопросов современной лингвистики является соотношение текста и дискурса. Кроме того, он имеет фундаментальное значение для интерпретации этих терминов. Бесспорным является лишь то, что данные понятия взаимозависимы. Если большинство лингвистических дисциплин и понятий имеют длительную историю существования и общепризнанное определение, то термины ˝дискурс˝ и ˝текст˝ еще не получили адекватного толкования из-за их сложности. Оба они требуют ряда лингвистических исследований, так как являются достаточно объемными и спорными.

Эмиль Бенвенист и Зелиг Харрис заложили традицию выделения различных объектов исследования: в 50-е годы XX в. Эмиль Бенвенист впервые применил общепринятое для французской лингвистики понятие *discours* в новом значении – как характеристика ˝речи, присваиваемой говорящим˝; Зелиг Харрис в 1952 г. опубликовал статью ˝Discourse analysis˝, рассматривающую метод дистрибутивного анализа по отношению к сверхфразовым единствам [Harris 1952: 12]. Бенвенист определяет дискурс как описание позиции говорящего в высказывании, для Харриса объектом анализа является последовательность высказываний [Benveniste 1985: 79].

Нередко ученые отождествляют дискурс с текстом, являющимся сложным лингвистическим знаком как результат процесса речеобразования. Например, Н.Д.Арутюнова определяет дискурс как ˝связный текст вместе с экстралингвистическими – прагматическими, социокультурными, психологическими и другими – факторами; текст, взятый в событийном аспекте; целенаправленное социальное действие как компонент взаимодействия людей и механизмов их сознания (когнитивных процессов)˝ [Арутюнова 1990: 136-137].

В последнее время структурно-семантические параметры текста рассматриваются учеными в соотношении с определенными признаками; существует ряд объективных признаков и для дискурса, к которым относятся завершенность, целостность, лексическая, грамматическая и смысловая связность, а также композиционная завершенность. При определенных условиях лингвисты считают правомерным расссмотрение текста как дискурса. Лингвистическое изучение текста является многоаспектным: оно раскрывает как языковой инвентарь, так и связь факторов (языковых и внеязыковых), создающих то или иное речевое произведение. Теория дискурса представляет собой одно из направлений данного анализа [Benveniste 1959: 95]. Быстрое развитие теории дискурса в современной лингвистике привело к необходимости разграничить сущность ее понятий, выявления и научного исследования их признаков.

Способы соотнесения рассмотренных понятий объяснены лингвистами различно. Так, А.С.Кубрякова отмечает, что важным для дискурса является функциональное направление и коммуникативно-прагматическая действенность; текст имеет знаковый (семиотический) характер, его основные признаки – информационная самодостаточность, целеустремленность, протяженность [Кубрякова 2004: 510]. В.И.Карасик рассматривает взаимосвязь текста и дискурса как ˝процесс – результат˝: дискурс – это текст, погруженный в ситуацию общения, или это общение с помощью текста [Карасик 2007: 278]. Н.С.Болотнова сравнивает текст, который можно понять прежде всего, по ее мнению, с помощью лингвистических категорий, с дискурсом, которое является понятием многоаспектным. Оно тесно взаимодействует с категориями логики, психологии, философии и направлено на человека и его опыт. Толкование литературного дискурса обобщает ас-

пекты модели дискурса: лингвистические, философские, идеологические [Болотнова 1998: 244].

В лингвокультурологическом подходе анализа дискурс рассматривается как лингвокультурная стратегия в единстве ее креативного, референтного и рецептивного аспектов. Ее цель заключается в определении и воплощении языковой картины мира автора и метода ее восприятия читателем, чем отмечается интерактивный характер дискурса [Тюпа 2001: 24]. В социолингвистическом подходе дискурс представляет собой целенаправленное вербализированное социальное действие, составляющая коммуникативной и когнитивной деятельности человека. Общим признаком для рассмотренных направлений является лингвокогнитивный аспект исследований [Шаховский 2008: 9].

Таким образом, в современной лингвистике при исследовании любых текстов необходим дискурсивный анализ. В текстах указаны авторские цели, которые расшифровывают участников коммуникации при анализе семантико-содержательной сущности текста. В художественном дискурсе эффективно отображены аксиологические ориентиры эпохи и нации. Разграничивая понятия ˝дискурс˝ и ˝текст˝, теория дискурса отмечает деятельностный и динамический аспект языка: ˝дискурс˝ представляет язык как действие, принимающее во внимание влияние экстралингвистических факторов при коммуникации.

**Литература**


Арутюнова Н.Д. Дискурс / Н.Д.Арутюнова // Лингвистический энциклопедический словарь / гл. ред. В.Н.Ярцева. – М.: Сов. Энциклопедия, 1990. – С.136-137.

Болотнова Н.С. Об изучении ассоциативно-смысловых полей слов в художественном тексте / Н.С.Болотнова. – Санкт-Петербург: Мысль, 1998. – С.242-247.

Карасик В.И. Языковые ключи / В.И.Карасик. – Волгоград: Парадигма, 2007. – 520 с.

Кубрякова Е.С. Язык и знание: На пути получения знаний о языке. Части речи с когнитивной точки зрения. Роль языка в познании мира / Е.С.Кубрякова. – Москва : Языки славянской культуры, 2004. – 560 с.

Тюпа В.И. Аналитика художественного. Введение в литературоведческий анализ / В.И.Тюпа. – Москва: Лабиринт; РГГУ, 2001. – 192 с.

Шаховский В.И. Лингвистическая теория эмоций [монография] / В.И.Шаховский. – Москва : Гнозис, 2008. - 416 с.

Benveniste E. On Discourse / E.Benveniste // The Theoretical Essays: Film, Linguistics, Literature. – Manchester: Manchester Univ. Press, 1985.

Benveniste E. Les relations de temps dans le verbe I'ranaais / E.Benveniste // Bulletin de la Societe de lingvistique de Paris. – 1959. – №1. – P.54.

Harris Z. Discourse analysis / Z.Harris // Language. – 1952. – V.28. – №1. – P.1-30.

**Харисов Фираз Фахразович**
Казанский (Приволжский) федеральный университет
УДК 378

## Формирование компетенций у учащихся: лингвометодический аспект

*компетенция, лингвометодика, коммуникативная компетенция, стандарт, татарский язык*

В настоящее время накопленные знания без выработки практических навыков сами по себе не могут решить проблему подготовки к внешкольной деятельности. В современной лингвометодике эта проблема ставится в более широкой и иной плоскости: целью получения знаний является не только приобретение новой информации и умений, но и формирование у учащихся необходимых компетенций для подготовки к практической работе – социализации.

В конце XX века в методике преподавания языков стал использоваться термин ˝компетенция˝.

К числу компетенций, принятых в 1996 году на симпозиуме в Берне в рамках проекта ˝среднее образование в Европе˝, относятся:

1. Экономико-политическая компетенция, или готовность к решению проблем, возникающих в повседневной жизни.
2. Информационная компетенция.
3. Коммуникативная компетенция.
4. Социально-культурная компетентция.
5. Компетенция готовности к обучению на протяжении всей жизни [Соловьева 2002: 11-14; 228].

При обучении татарскому языку на основе Стандарта для развития и совершенствования универсальных познавательных компетенций приоритетными являются:

- ❖ практическое освоение проектно-исследовательских навыков;
- ❖ обучение навыкам чтения и работы с полученной информацией;
- ❖ применение методов познания на практике, овладение приемами логического мышления на уроках языка.

Освоенные в начальных классах навыки работы с информацией совершенствуются, развиваются, за счет чего достигаются следующие результаты:

- ❖ умение давать самостоятельные объяснения, систематизируя, сравнивая, проверяя и обобщая информацию, содержащуюся в готовых источниках;
- ❖ умение работать с отдельными текстами, выделив основную мысль, лаконично и точно изложив ее в виде тезиса или графической формы;
- ❖ умение заполнять таблицы и схемы, дополнять графические изображения с помощью различных источников и современных технических средств, грамотно и правильно пользоваться сетью Интернет.

В развитии познавательных компетенций учащихся в соответствии со стандартом предполагается достижение следующих результатов:

- ❖ изучение истории и географии, культурного наследия и традиций родного края на уроках татарского языка;
- ❖ знание хронологии общественно-политического устройства Родины, произошедших в ней исторических событий, а также государственных символов – герба, флага и гимна, государственных праздников;
- ❖ осознание как представителя отдельной нации своих прав и обязанностей, понимание и знание национальных традиций, культуры и ценностей.

Не отрицая значимости вышеперечисленных компетенций в учебной деятельности, при обучении татарскому языку важно формировать следующие компетенции:

1. Коммуникативная компетенция. В лингвометодических исследованиях последних лет здесь же рассматриваются лингвистическая, общественно-лингвистическая, общественно-культурная, дискурсивная и стартегическая компетенции [Крючкова 2011: 73-74].

2. Лингвистическая компетенция предполагает грамматически правильное формирование речи учащихся, обладание знаниями, позволяющими организовать свободное общение в устной и письменной форме по различным ярусам изучаемого языка (лексике, фонетике и грамматике).

3. Компетенция в области национальной культуры, т.е. овладение языком в национально-культурной плоскости как средством духовного, эстетического воспитания и образования обучающихся; умение работать с текстами, отражающими национальную самобытность, знание особенностей быта, обычаев; понимание того, что язык является средством общения и взаимопонимания между народами; понимание неразрывности истории языка и жизни народа.

4. Социально-культурная компетенция – относительно новое понятие в системе образования. Она входит в состав коммуникативной компетенции, связанной с формированием общественно-культурной компетенции, и является ее частью.

Большое место в стандарте нового поколения отводится вопросам подготовки учащихся к общественной жизни. Такая деятельность – непрерывно протекающий процесс, изменяющий и развивающий психические качества личности. Важнейшая его часть приходится на детские и юношеские периоды человека, так как в это время закладывается фундамент готовности к будущей жизни, усиливается интерес к окружающим явлениям.

В целях формирования различных компетенций в общеобразовательных организациях работу по подготовке и воспитанию обучающихся к социализации необходимо организовать по следующим направлениям:

❖ воспитание чувства гражданственности, патриотизма, уважения к правам, свободам и обязанностям человека;

❖ воспитание любви к России, Татарстану и родному краю в целом;

❖ формирование таких положительных черт характера, как справедливость, милосердие, уважение к родителям и другим людям, ответственность, забота о старших и младших;

❖ уважение к людям, государственным институтам, обществу, уважение к народам и их культурам;

❖ служение Отечеству, желание жить с чувством общественной ответственности за настоящее и будущее страны;

❖ развитие внутреннего мира человека, обладающего красотой, гармонией, самовыражением в творчестве и искусстве, духовным и эстетическим развитием личности и т.д.

Таким образом, коммуникативная компетенция является ведущей, составляющей основу других компетенций. Для успешного развития современного образования необходимо формировать метапредметные и предметные умения и навыки, развивать мыслительные способности учащихся, рассматривать воспитательную цель как совокупность ожидаемых результатов и компетенций от образования.

**Литература**

Крючкова Л.И. Русский язык как иностранный / Л.И.Крючкова. – М.: Флинта; Наука, 2011. – 215 с.

Соловьёва Е.Н. Методика обучения иностранным языкам: базовый курс / Е.Н.Соловьёва. – М.: Просвещение, 2002. – 256 с.

Харисов Ф.Ф. Рус телендә сөйләшүче балаларны татарчага өйрәтүнең башлангыч чоры / Ф.Ф.Харисов. – Казан: КДПИ, 1996. – 48 б.

**Хасанова Алина Рафаилевна**
Казанский (Приволжский) федеральный университет
УДК 81

## Татар һәм башкорт телләрендә туганлык атамаларыннан ясалган сүзләр

*туганлык атамалары, сүзьясалышы, кушымчалар, ата, ир*

Сүз телнең берәмлеге буларак предмет яки реаль дөнья күренешләре белән бәйләнештә. Төрле мәдәнияттә предмет яки күренешләр генә түгел, ә алар турында мәдәни күзаллаулар да төрле булырга мөмкин. Чөнки алар төрле дөньяларда һәм мәдәниятләрдә яшиләр, функцияләшәләр. Башка сүзләр белән әйткәндә, тел дөньяны сурәтләү генә түгел, ул безнең аңыбызда идеаль дөнья төзи.

Лексика тематик катламнары арасында барлыкка килү һәм алар тарафыннан билгеләнә торган төшенчәләрнең ныклыгы буенча беренче урыннарның берсе, туганлык мөнәсәбәтләрен бирүче лексика катламы алып тора. Мондый сүзләр туган телләрне һәм төп сүз фондын чагыштырып өйрәнү мәсьәләләренә багышланган төрле эшләр авторларының теге яки бу нәтиҗәләрен ныгыту өчен еш җәлеп ителә.

Туганлык атамалары системасы халык тарихының бик борынгы чорында ук формалаша һәм, шуңа күрә дә, тарих өчен, тел тарихы өчен аеруча әһәмиятле лексик төркемне тәшкил итә. Тикшеренүләр күрсәтүенчә, аерым сөйләшләрдә шул төбәктәге кайчандыр йотылган этник төркемнәрдән кергән атамалар да табыла.

Башкорт туганлык системасының тасвирламасы һәм тарихи интерпретациясе беренче тапкыр С.И. Руденконың башкортлар турындагы китабында бирелә. Лингвист Х.Г. Йосыповның башкорт телендә туганлык атамаларын өйрәнүгә багышланган мәкаләсендә туганлык терминологиясе лексиканың бер өлеше буларак тикшерелә. Әмма шул ук вакытта, автор кардәшлек системасы нигезенә салынган кайбер принципларны төгәл билгели: ˝яшь үзенчәлекләре, җенси аерымлыклар һәм буыннар аермасы˝ [Йосыпов 1959: 124].

Сүз ясалышы проблемаларына һәрвакыт зур игътибар бирелгән, әмма ул XX гасырның 50 нче елларында аеруча интенсив өйрәнелә башланган.

Төрле ысуллар ярдәмендә ясалган сүзләр билгеләп үтелгән татар һәм башкорт телләрендә аеруча күп очрый.

Татар һәм башкорт телләрендәге терминнардан төрле ысуллар белән ясалган сүзләр каралды. Аларны тикшереп түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

Татар телендә: АТАЛЫК – 1) Ата булу*. (Совет иленең һәрбер намуслы карты эшләргә тиешле булган аталык бурычымны гына үтим*. Т.Гыйззәт). 2) Ата җенестән, нәсел өчен калдырылган кош-корт яки хайван. 3) *биол*. Чәчәкләрдә ата җенестән булган серкә күзәнәк [242 Б.], исем, ис.+ -лык/-лек (ата+лык).

АТАКАЙ – 1) Атаны яратып телгә алу яки ялварып, ялынып, аңа мөрәҗәгать итү, эндәшү сүзе. (*Бу минутта Митьканың атакайга ошарлык берәр сүз әйтәсе килә иде.* З.Фәтхетдинов.) 2) сөйл. Өлкән яшьтәге ир кешегә мөрәҗәгать сүзе 3) Христиан динендә: рухани. (*Өлкә җитәкчесе инициативасы белән оештырылган бу чарада Түбән Новгородһәм Арзамас митрополиты Николай атакай катнашты.* Мәдәни җомга.) [241 Б.]., исем, ис.+ -кай/-кәй (ата+кай).

АТАЛА́РЧА – 1) Ата буларак 2) Ата кебек якын итеп, кайгыртып. (*Кыскасы, үз кешеләре турында аталарча кайгырта ул*. М.Хәбибуллин) [241 Б.]., рәвеш, ис.+ -ча/=чә (аталар+ча).

АТАЛАНУ – 1) бот. Серкә күзәнәге белән күкәй күзәнәкнең үзара кушылуы, серкәләнү 2) сөйл. Хайваннарда җенси кушылу [241 Б.]., фигыль, исем + -лан/-лән (ата+лан).

Башкорт телендә: АТАЛЫ – 1) Атаһы булған, атаһы бар. Аталы бала. 2) Ата енесенә ҡауышҡан; аталанған. Аталы йомортҡа., сыйфат, ис.+ -лы/-ле (ата+лы).

АТАЛЫК – 1) Ҡайһы бер ҡош-ҡорт һәм үҫемлектәрҙең ата енеслеһе. (*Ҡаҙҙың аталыгы. Өйрәктең аталыгы.)* 2) Ата енесле. Аталыҡ күҙәнәк., исем, ис.+ -лыҡ/-лек (ата+ лыҡ).

Татар һәм башкорт телендәге “АТА” дигән туганлык атамасыннан икесендә дә бертөрле“аталык”, “аталы” сүзләре кушымчалау ысулы белән ясалганнар. Лексик-семантик яктан мәгънәләре охшаш. Шулай ук татар теледә “атакай”, аталарча”, “аталану” сүзләре ясалган.

2) Татар телендә: ИРДАР – Тәвәккәл, батыр, чын ир. (*Авторлар, күрәсең, кыю һәм ирдар кеше портретын сурәтләүләренә ихлас күңелдән ышаналар.* Тигез гомер итегез!) [582 Б. ], сыйфат, ис. + -дар/-дәр (ир+дар).

ИРДАРЛЫК – Ирләрнең тәвәккәллек, батырлык, гайрәтлелек, булдыклылык, тугрылык һ.б. уңай сыйфатлары. (*Адәмнәр арасында ирдарлык бетеп килә. Ир-ат арасында феминизация – ˝катыншаклану˝ процессы бара.* А.Тимергалин) [582 Б. ], исем, сыйфат + -лык/-лек (ир+дар+лык).

ИРЛЕ – Кияүгә чыккан, ире булган, ирдәге. (*Юк, Нинаның да ире ба, ул да бүтәннәр рәтеннән ирле хатынга исәпләнеп йөри.* Ә.Еники.) Сыйфат, ис.+ -лы/-ле (ир+ле).

ИРЛЕК – 1) Ир кеше булу. (*Гадилнең ирлек дәрәҗәсен күтәрә, кәефен яхшырта, тормышын ямьли иде.* М.Маликова). 2) Ир кеше булу куәте. (- *Болай булганчы, үләсе калган... Ир-ат өчен ирлеген югалтудан да зур кайгы юк, күрәмсең.* Ә. Галиев). 3) сөйл. Ир кешенең җенес әгъзасы. 4) күч. Батырлык, кыюлык, егетлек. (*Балаларда ирлек, егетлек сыйфатлары тәрбияләү – белем бирү белән бер дәрәҗәдәге бурыч.* М.Мәһдиев). Исем, ис.+ -лык/-лек (ир+лек).

ИРСЕЗ – 1) Ире булмаган. (*Гомумән ир заты булмаган. Ирсез йортта какмаган җир һаман табылып тора...*М.Маликова). 2) Ирдән башка. (*Ирсез яши торган ханымнарга да тартмаганнар.* Ә.Моталлапов). 1. сыйфат, 2. рәвеш, ис.+ -сыз/-сез (ир+сез).

Башкорт телендә: ИРЛЕ – Иргә сыҡҡан, ире бар. Ирле ҡатын., сыйфат, ис.+ -лы/-ле (ир+ле).

ИРЛЕК – 1. Ир булыу хәле. 2. Ирҙәргә хас сифат; батырлыҡ, ҡыйыулыҡ. (*Был дошмандар менән көрәшергә көслө гәйрәт, ҙур ирлек кәрәк.* М. Ғафури. *Ир ирлеген итер, моратына етер.* Мәҡәл.), исем, ис. + -лык/-лек (ир+лек).

ИРҺЕҘ – Ире булмаған, ире юҡ. Ирһеҙ ҡатын. *(— .. Ниңә үпкәләнең, әйт инде,— тигәс: – Мин ярлы ҡыҙы шул, һин мине һанга һуҡманың, .. мин дә ирһеҙ ҡалмам әле, әйҙә, бай ҡыҙҙарын ал,., тине Зөләйха.* Т. Йәнәби.), сыйфат, ир+ -һыҙ/ -һеҙ, -һоҙ/ -һөҙ (ир+ һеҙ).

Татар һәм башкорт телләрендәге “ИР” нигезендә кушымчалау ысулы ярдәмендә “ирле”, “ирлек”, “ирсез” сүзләре ясалган. Лексик-семантик яктан мәгънәләре охшаш.

3) Татар телендә: АПАЛЫ́-СЕҢЕЛЛЕ - Апа белән сеңел, апа белән сеңел бергә; апа белән сеңел кебек. (*Юк, Рабига белән Җамал һич кенә дә апалы-сеңелле бертуганнар була алмый.* Ф.Сафин) [193 Б.], рәвеш, ис.+ -лы/-ле (аплы+лы – сеңел+ле) һәм исемнәрдән ясалган парлы сүз.

АПАЛЫ́-ЭНЕЛЕ – Апа белән эне, апа белән эне бергә; апа белән эне кебек. (*Апалы-энеле, икәүләшеп, бакчага керделәр.* А.Гыйләҗев. *Алар, апалы-энеле, һәр эшне бергәләп башкарырга тырышалар иде.* Х.Камалов) [193 Б.], рәвеш, ис.+ -лы/-ле (апа+лы – эне+ле) һәм исемнәрдән ясалган парлы сүз.

Башкорт телендә: АПАЛЫ-ҺЕҢЛЕЛЕ – Апай менән һеңле бергәләп. Апалы-Һеңлеле килгәндәр., рәвеш, ис.+ -лы/-ле (апа+лы – һеңле+ле) һәм исемнәрдән ясалган парлы сүз.

АПАЛЫ-ЭНЕЛЕ – Апай менән эне бергәләп. Апалы-энеле укып йөрөйҙәр, рәвеш, ис.+ -лы/-ле (апа+лы – эне+ле) һәм исемнәрдән ясалган парлы сүз.

Татар һәм башкорт телләрендә “АПА”, “СЕҢЕЛ” терминнарыннан кушымчалау ысулы һәм әлеге ике термин ярдәмендә “апалы-сеңелле”, “апалы-энеле” сүзләре ясалган. Мәгънәләре ягыннан ике тел дә охшаш.

Шулай, шуны әйтергә мөмкин: татар һәм башкорт телләрендәге туганлык атамаларыннан ясалган сүзләрдә иң күбе –лык/лек сүз ясагыч кушымчалары кулланыла. Икенче урында –лы/ле кушымчалары тора. Синтаксик ысулларга килгәндә, берене урында парлы сүзләр. Ә икене урында тезмә сүзләр тора, кушма сүзләр сирәк очрый. Туганлык терминнарыннан ясалган сүзләрнең күбесе ике телдә дә бертөрле һәм мәгънәләре ягыннан охшаш. Кайбер аерымалы сүзләр дә очрый.

Лексик-семантик берәмлекләр арасындагы системалы бәйләнешләр төрле факторларга бәйле була һәм төрле дәрәҗәдә чагылыш таба. Сүзләрне төркемләү, чынбарлыктагы күренешләрнең уртак якларына бәйле дә, семантик уртаклыкка, охшашлыкка бәйле дә булырга мөмкин. Әлеге үзенчәлекләрне өйрәнү тел белеме, тел тарихы өчен бик тә әһәмиятле.

**Әдәбият**


Акилова М.Ф. Некоторые термины родства в турецком, башкирском и русском языках / М.Ф.Акилова // Вестник Башкирского университета. – 2019. – Т.24. – №3. – С.2-3.

Ганиев Ф.Ә. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Ф.Ә.Ганиев. – Казан: Матбугат йорты нәшр., 2005. – 848 б.

Рамазанова Д.Б. Атамаларда туганлык һәм гаилә мөнәсәбәтләре / Д.Б.Рамазанова. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. – 287 б.

Ураксин З.Ғ. Хәҙерге башҡорт әҙәби теленең аңлатмалы һүҙлеге / З.Ғ.Ураксин. – Өфө: ИИЯЛ УНЦ РАН, 2004. – 528 б.



**Хаялиева Раиля Ренатовна**
Казанский (Приволжский) федеральный университет


УДК 80/81.246.2


## Балаларның сөйләм телен өйрәнү мәсьәләсенә карата


*онтолингвистика, балалар сойлэме, татар теле, тел белеме, аралашу системасы*


Баланың дөньяны танып белүе олыларныкына охшамаган, шактый үзенчәлекле процесслар аша бара, шунлыктан телне куллануы, сөйләм оештыруы аерыла. Балаларның сөйләм телен лингвистика яки онтолингвистика өйрәнә. Шулай ук балалар сөйләме психологик тикшеренүләр объекты да булып тора.

Балаларның сөйләм теле, бала психологиясе, гомумән балалар дөньясына бәйле фәнни тикшеренүләр чагыштырмача яңа күренеш булып тора. Балалар психологиясе белән беренче фәнни кызыксынулар XIX гасырда башлана. Мондый эзләнүләр балалар сөйләмен өйрәнүгә юл ача. 1876 елда ˝Mind˝ журналында күренекле философ, психолог һәм тарихчы Ипполит Тэн кечкенә кызының сөйләмен теркәп барган көндәлеген бастырып чыгара. Аннан соң инде Чарльз Дарвин, алман физиологы Вильям Прейер үз балаларының коммуникатив үзенчәлекләрен туплап барган көндәлекләре дөнья күрә. Әлеге журналда басылган чыганаклар балалар сөйләм телен өйрәнүнең эти-әниләр көндәлегенә нигезләнгән беренчел чоры булып тора.

XIX гасыр ахырында рус тел белемендә баланың үсеш психологиясенә, сөйләменә багышланган беренче хезмәтләр күренә башлый. Россиядә балалар сөйләме фәнни тикшеренүләр предметы буларак XX гасыр башында зур популярлык казана. Тикшеренүләр нигездә балалар сөйләме тупланган көндәлекләр материалында башкарыла Иң күренекле хезмәтләрнең берсе булып язучы К.И.Чуковскийның “От двух до пяти” китабы тора. 20 нче еллар башында К.И.Чуковский балалардан ишеткән сүзләрне, сөйләмнәрне язып бара һәм бала тарафыннан иҗат ителгән гадәти булмаган сүзләр туплаган кита-

бын бастыра һәм бу китап тиз арада игътибар казана. Россиядә балалар сөйләме лингвистикасына нигез салучы булып галим А.Н.Гвоздев санала. Галим беренчеләрдән булып рус телендә сөйләшүче баланың туган телне куллану процессына фәнни тасвирлама бирә. Организмның индивидуаль үсешендә (онтогенез) сөйләм теленең кулланылышына багышланган хезмәтләре җитди фәнни тикшеренү нигезе булып тора [Горелов 2001].

Татар тел белемендә балалар сөйләменә кагылышлы фикерләр XX гасыр башында барлыкка килә. К.Насыйри, Г.Ибраһимов кебек күренекле галимнәрнең хезмәтләрендә бала сөйләменә кагылышлы фикерләрне очратырга була [Прейер 1912]. 1940-1950 елларда танылган методист М.Галимованың мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм үзенчәлегенә багышланган хезмәтләре басыла.

Балалар сөйләмен өйрәнүгә татар галимнәре һәм тел белгечләре М.Х.Корбангалиев, М.А.Фазлуллин, А.Ш.Асадуллин, Р.А.Кадыйрова, М.Ф.Кашапова һ.б. зур көч куялар [Ушакова 2011].

Хәзерге фәндә телне үзләштерү, баланың сөйләм теле формалашу процессы белгечләрдә һәрвакыт зур кызыксынулар уята. Сөйләм теле үсеше, аның формалашу проблемалары белән укытучылар, логопедлар һәм психологлар шөгыльләнә. Балаларның тел үзләштерүе, конкрет бер телдә сөйләшә башлавы, психологик үзгәрешләрнең сөйләм эшчәнлегенә тәэсир итүе хакында күпсанлы фәнни хезмәтләр языла. Балаларның аерым бер телгә генетик дәрәҗәдә сәләтле булуы хакында да фәндә бәхәсләр бара.

Шунысы әһәмиятле: 3-4 ел эчендә бала катлаулы коммуникатив система, ягъни тел үзләштерү үзенчәлекләрен табигый рәвештә кабул итә дип санала.

Балаларның туган телне кабул итүе, өйрәнүе хакында галимнәрнең фикере икегә бүленә. Беренчеләре, баланың туганда конкрет милли тел үзләштерергә ярдәм итә торган механизмнары булмый, дип раслый. Икенчеләре балага тел өйрәнергә, кабул итәргә ярдәм итә торган аерым белемнәр генетика дәрәҗәдә килүен, “тел инстинкты” булуын исбатларга тырыша.

Тарихка күз салсак, телнең генетика буенча күчү-күчмәү мәсьәләсе элек-электән экспериментлар нигезендә дәлилләү омтылышы булган. Шундый экспериментларның берсе “Монгол империясенең гомуми тарихы” хезмәтендә тасвирлана. Әкбәр хан иң борынгы телне ачыкларга теләп, төрле милләттән булган 12 күкрәк баласын аналарыннан аерып сарайга яба. Аларны кайгыртырга телсез тәрбиячеләр билгелиләр. Балаларны беркем дә сөйләшергә өйрәтми. Хан Әкбәр, махсус тел өйрәтүче олы кеше булмагач, балаларның теле иң борынгы телдә ачылачак һәм шул рәвешле иң борынгы телнең кайсы тел икәнен ачыклаячакбыз, дип фикер йөрткән. 12 елдан соң балаларны дөньяга чыгаралар, әмма аларның берсе дә кеше телендә сөйләшмәгән, ихтыяҗларын ымнар аша гына белдерә торган балалар булып үсеп җиткәннәр [Кашапова 2009].

Фәндә шулай ук, хайваннар арасында үскән балаларның кеше телендә сөйләшә белмәве, баланың үзлегеннән генә сөйләшергә өйрәнә алмавын исбатлый торган “Маугли феномены” дигән күренеш бар. Йөз еллар дәвамында уздырылган фәнни экспериментлар шуны раслый: бала туганда, конкрет милли телне үзләштерү сәләте булмый. Димәк, “баланың кайсы телдә сөйләшә башлавы тәненә, чәченә, күзенә һ.б. билгеләренә карамый, ә аның тирәсендәге кешеләрнең нинди телдә аралашуына бәйле була. Чөнки ул телне башкалар, әйләнә-тирә (гаилә, мәктәп, тәрбиячеләр, урам һ.б.) тәэсирендә өйрәнә. Конкрет бер тел буыннан-буынга күчми, баланың нинди телдә сөйләшәчәге генетик яктан алдан билгеләнми. Баланың аерым органнары гына генетик дәрәҗәдә сөйләм механизмына яраклаштырылган. Бу тәгълиматны нәселдән-нәселгә күчеп килүче туган телне балага өйрәтү – әти-әнинең беренчел бурычы, хәтта җаваплылыгы дип тә аңларга кирәктер. Баланың фикерләве дә, сөйләме дә ана телендә ачылырга тиеш. Кеше милли үзаң белән табигать кушканча үссен, яшәсен өчен бу – иң беренче шарт, дип белдерә тел галиме Илдар Низамов [Насыйри 1974].

Бүгенге көндә баланың тел ачылу, сөйләшү сәләтен психологик һәм лингвистик яктан җентекләп өйрәнелә. Баланың аерым бер тел берәмлекләрен кулланып сөйләшә башлавы генетик дәрәҗәдә барлыкка киләме, әллә психологик үсеш дәверендә формалашамы дигән сораулар үзәккә куела.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, балаларның сөйләм телен өйрәнү тарихы төрле методлар һәм юнәлешләр белән билгеләнә. Беренчел чорда көндәлекләргә нигезләнгән балаларның сөйләм үзенчәлекләре, авазлар әйтелешенә зур игътибар бирелә, баланың тел өйрәнү сәләте, мөхитнең балаларның сөйләм теле формулашуына тәэсире, сөйләм структурасы, артикуляциясенә бәйле хезмәтләр дөнья күрә. Бүгенге фәндә галимнәр баланың туган телне кабул итү процесслары, психологик үзгәрешләр тәэсирендә барлыкка килгән сөйләм телен өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Татар телле балаларның сөйләм эшчәнлеген өйрәнгән хезмәтләр дә арта бара.

### Әдәбият


Белянин В.П. Психолингвистика: учеб. / В.П.Белянин; РАО, НОУ ВПО МПСИ. – 2-е изд. – М.: Флинта: МПСИ, 2011. – 416 с.

Горелов И.Н. Основы психолингвистики / И.Н.Горелов, К.Ф.Седов. – М., 2001.

Кашапова М.Ф. Балалар бакчаларында телдән сөйләмгә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре: монография / М.Ф.Кашапова. – Казан: ТДГПУ, 2009. – 120 б.

Насыйри К. Сайланма әсәрләр / К.Насыйри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – Т.1. – 340 б.

Прейер В. Душа ребенка. Наблюдения над духовным развитием человека в первые годы жизни / В.Прейер; пер. с 7-го нем. изд.; под ред. В.Ф.Динзе. – СПб., 1912. – 299 с.

Ушакова Т.Н. Рождение слова. Проблемы психологии речи и психолингвистики / Т.Н.Ушакова; под ред. Журавлева А.Л. [Электронный ресурс]. – М.: Институт психологии РАН, 2011. – 528 с. Режим доступа http://www.biblioclub.ru/book/86269/.



**Чжоу Цзяннань**

Казанский (Приволжский) федеральный университет



УДК 81


## Развитие коммуникативной компетенции китайских студентов на занятиях по русскому языку как иностранному (на примере русской гастрономической лексики)


*коммуникативная компетентность, русский язык как иностранный, методика преподавания, китайские студенты*


Практический опыт преподавания русского языка китайским студентам в научной литературе показывает, что китайские студенты обладают более выдающимися способностями в письме, чтении и т.д., в то время как их коммуникативные навыки оставляют желать лучшего. Несмотря на публикации в этой области, подобные вопросы до сих пор не до конца изучены в современном российском преподавании.

Наша работа посвящена обучению лексике, связанной с едой, на занятиях русским языком как иностранным. Цель нашего исследования заключалась в том, чтобы определить методы обучения, эффективные для повышения коммуникативной компетенции китайских студентов на занятиях по русскому языку как иностранному.

Для достижения данной цели были поставлены следующие задачи:

1) рассмотреть теории, связанные с преподаванием русского языка как иностранного;

2) собрать материал о еде;

3) исследовать возможности лексики, связанной с едой, в практике преподавания русского языка как иностранного;

4) предложить способы улучшения коммуникативных навыков китайских студентов и разработать модель образования.

Мы выявили, что особая традиционная этническая пищевая лексика может вызвать трудности в понимании у изучающих язык. Существует множество таких единиц: например, борщ, шаурма, компот и т.д. Кроме того, китайские студенты более интровертивны и менее склонны к общению с носителями русского языка. Наконец, трудности общения вызваны психологическими проблемами у самих студентов.

Соответственно, необходимо предложить некоторые методы, которые помогут улучшить коммуникативные навыки китайских студентов:

а) метод тематического обсуждения. Преподаватель заранее задает домашнее задание. Студенты находят материалы по теме и представляют результаты своих презентаций в классе.

б) метод сценарного моделирования. Преподаватели могут обучать студентов практическим навыкам, создавая сценарии для конкретных ситуаций, например: как купить продукты в магазине, как заказать блюда в ресторане и т.д.

в) мультимедийный метод. Преподаватель использует современные средства обучения в сочетании с традиционными методами преподавания.

**Литература**


Антонова Е.С. Методика преподавания русского языка. Коммуникативно-деятельностный подход / Е.С.Антонова. – М., 2007.– 205 с.

Вагнер В.Н. Лексика русского языка как иностранного и ее преподавание / В.Н.Вагнер. – М.: Флинта: Наука, 2006. – 145 с.

Зимняя И.А. Психологические аспекты обучения говорению на иностранном языке / И.А.Зимняя. – М., 1989.– 222 с.

Щукин А.Н. Лингводидактический энциклопедический словарь / А.Н.Щукин. – М.: Астрель: АСТ: Хранитель, 2007. – 746 с.



**Шайхулов Юнус Данисович**

Казанский (Приволжский) федеральный университет



УДК 81-26


## Инглиз теле сүзлекләре һәм төрки сүзләр


*төрки сүзләр, алынмалар,сүзлекләр, телләр, инглиз теле*


Тел галимнәре теләсә кайсы телнең үсештә-үзгәрештә булуын даими рәвештә искәртеп тора. Телнең лексик катламы, билгеле булганча, социаль факторларга тиз бирешә. Башка халыклар белән мөнәсәбәткә кереп, икътисади, мәдәни, сәяси бәйләнешләр булдыру нәтиҗәсендә, телдәге сүзлек составы сизелерлек дәрәҗәдә арта. Бу вакытта, нигездә, яңа төшенчәләр һәм реалияләр барлыкка килә. Глобальләшү шартларында әлеге процесс даими рәвештә җәелә, чөнки тормышка бәйле үзгәрешләр төрле милләтләр арасындагы аралашуларның артуына китерә.

Илләр арасында сәяси һәм икътисади мөнәсәбәтләр үсү белән бәйле рәвештә, инглиз теленә Азия, Африка, Көньяк һәм Төньяк Америка һәм Австралия территориясендә яшәүче күп кенә халыклар телендә булган сүзләр үтеп керә. Галимнәр хәзерге инглиз телендә якынча 50 телдән кергән алынма яши дигән фикердә тора. Алынма сүзләр ярдәмендә телнең лексик байлыгы үсә, шулай ук алынмалар сүзләрнең яңа тамыры, сүз ясалыш элементлары һәм төшенчәләре барлыккак килүгә этәргеч бирә һәм кешелекнең иҗтимагый яшәеш шартларына яраклаштырыла. Алынмаларның үтеп керүенә нәрсәләр йогынты ясаган дигән сорауга илләр һәм дәүләтләр арасындагы сәүдә мөнәсәбәтләрен актуаль җавап итеп китерергә мөмкин. Шуңа күрә дә инглиз

телендәге алынмаларның шактый өлеше Англиягә үтеп кергән эшләнмәләрнең исемнәре белән бәйле.

Шәрыкъ илләре белән сәяси, икътисади һәм мәдәни мөнәсәбәтләрнең тыгыз булуы инглиз теленең сүзлек байлыгында тирән эз калдырган. Ягъни инглиз теленә әлеге илләрдәге халыкларның сөйләме, көнкүреше, тормышында булган шактый гына сүзләр үтеп кергән. Нигездә, инглиз телендә күпләгән гарәп һәм төрки алынмаларны очратырга мөмкин.

Инглиз теленең лексик составында алынмалар шактый зур әһәмияткә ия. Чит тел элементлары башка телгә үтеп керә һәм бөтенләй башкача "яши" башлый. Кайбер очракларда алар алынмаларны кабул итеп алучы телгә килеп керү белән, шул телдәге фонетик, грамматик, сүз ясалыш нормалары нигезендә үзгәреш кичерә һәм шул рәвешле, сөйләмгә дә күчә. Ә башка очракларда алынма сүзләр милли үзенчәлекләрне саклый һәм милли колоритны җиткерүдә мөһим роль уйный.

Төрки телләр, башка телләр белән беррәттән, инглиз телендә дә шактый тирән эз калдырган. Моңа түбәндәге халыкларның телләрен кертеп карарга мөмкин: балкарлар, гагаузлар, казаклар, караимнар, үзбәкләр, каракалпаклар, татарлар, төрекләр, төрекмәннәр, карачайлар һ.б. Төрле тарихи чорларда төрки халыклар Евразия континенты территориясендә үз дәүләтләрен булдыра. Моңа Һуннар империясен, Төрки каганатны, Алтын Урда дәүләтен һ.б. кертеп карарга мөмкин. Галимнәр исәпләвенчә, инглиз телендә 400 гә якын төрки алынма бар. Шуларның 55 % – этнографик реалияләр, 26 % – иҗтимагый-сәяси юнәлештәге сүзләр, 19 % – табигый реалияләр тәшкил итә.

Шунысын да әйтергә кирәк: төрки алынмаларның инглиз теленә уңышлы гына үтеп кереп "яшәп" киткәннәре аз түгел. Аларны стилистик яктан нейтраль алынмалар дип атарга була, чөнки әлеге сүзләр әдәбиятта да, сөйләм телендә дә шактый иркен файдаланыла. Төрки алынмаларның инглиз телендәге фразеологизмнар составында очравы моның ачык мисалы булып тора. Төрки алынмаларны инглизләр еш куллана. Кайчандыр инглиз теленә үтеп кергән алынмаларны инглиз халкы үз сүзләре кебек файдалана һәм шуңа күрә дә алар инглизләр сөйләмендә еш күзәтелә. Шулай ук төрки алынмалар аша инглиз телендә сөйләшүчеләрнең дөнья картинасына булган карашлары да шактый киңәя төшә.

Төрки телләрнең башка телләр белән мөнәсәбәткә керү күренешен өйрәнү хәзерге лингвистиканың үзәк мәсьәләләреннән санала. Төрки алынмаларның бүтән телләргә, шул исәптән, инглиз теленә дә үтеп керү сәбәпләрен, вакытын һәм юлларын тикшерү һәм өйрәнү, аларның башка телдә яраклашып китү үзенчәлекләре тарихи лексикологиядә дә актуаль булып кала. Моннан тыш, инглиз теле һәм төрки телләр кебек төрле төзелешкә ия булган телләрнең үзара мөнәсәбәткә керү күренеше дә бик кызыклы. Хезмәтнең актуальлеге шуның белән дә бәйләп аңлатыла.

Эш барышында түбәндәге бурычлар күз алдында тотылды:

1) Тел белемендә алынмалар үтеп керү процессын өйрәнү;

2) Инглиз телендә төрки алынмаларның ролен ачыклау;

3) Инглиз телендәге төрки алынмаларның лексик-семантик үзенчәлекләрен тикшерү;

4) Инглиз телендәге төрки алынмаларның грамматик-стилистик үзенчәлекләрен өйрәнү (сүз ясалышы, морфология, синтаксис).

Сүзлек мәкаләләре тикшерү материалы буларак кулланылды.

Хезмәтне башкарганда, безгә түбәндәге методларга нигезләнеп эш итәргә туры килде:

1) Тел белеменә алынмаларның үтеп керү күренеше, төрки алынмаларга хас үзенчәлекләр, инглиз телендә төрки алынмаларның яшәеше турында теоретик материал туплаганда, теоретик методка таяндык;

2) Инглиз теленә һәм төрки телләргә хас үзенчәлекләрне барлаганда, чагыштыру методына нигезләндек;

3) Сүзлекләргә кертелгән төрки алынмаларның тематик яктан бүленешен, мәгънә үзгәрешләрен, сүз ясалыш үзенчәлекләрен тикшергәндә, күзәтү методы кулланылды.

Тарихилык, системалылык, параллельлек принциплары хезмәтнең методологик нигезен тәшкил итә.

Хезмәтне башкарганда Р.Г.Әхмәтьянов, И.И.Биккинин, В.К.Журавлев, Ф.С.Сафиуллина, Б.А.Серебренников, Р.М.Болгарова, Э.А.Исламова, Р.Р.Җамалетдинов, Р.А.Юналеева, Г.Рамстедт, В.Котвич, Е.Поливанов, Б.Владимирцов, А. Щербак, Б.Юнусалиев, Б.Орузбаева, В.Рассадин, К.Мусаев, А.Х.Нуриева, В.Х.Хаков һ.б. кебек тел галимнәренең хезмәтләренә таянып эш иттек.

Әлеге хезмәт төрле төзелешкә ия телләрдәге төрки алынмаларны комплексы һәм системалы рәвештә чагыштырып өйрәнү юнәлешендәге татар телендәге беренче хезмәт булып санала. Биредә лексик берәмлекләрнең сүзъясалыш үзенчәлекләре, мәгънә төсмерләре, тематик яктан бүленеше күздә тотыла.

Төрки алынмаларны өйрәнү юнәлешендәге әлеге хезмәтнең теоретик әһәмияте түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) инглиз телендәге төрки алынмаларны өйрәнүдә заманча тикшерү алымнары кулланыла;

2) төрки алынмаларның лексик-семантик бүленеше тәкъдим ителә;

3) хезмәттә төрки алынмаларга бирелгән характеристика башка телләргә үтеп кергән төрки алынмаларны тикшерүдә дә кулланыла ала.

Хезмәтнең практик әһәмияте түбәндәгедән гыйбарәт: хезмәттә күрсәтелгән нәтиҗәләрне лингвистика, лингвокультурология, лексикология кебек фәннәр буенча лекция һәм гамәли дәрес материаллары төзегәндә кулланырга мөмкин.

**Әдәбият**

Гил Н.Ф. Древнетюркские слова в современных языках. Сравнительное языкознание : этимологический словарь / Н.Ф.Гил. – М.: Модерат, 2013. – 134 с.

Егер О. Всемирная история: В 4 т. Т.2. Средние века. – М.: ООО ˝Издательство АСТ˝, 2000. – 696 с.

Мухамметдинов Р.Ф. Тюрки в истории мировой цивилизации / Р.Ф.Мухамметдинов. – М.: ООО ˝Грумант˝, 2018. – 155 с.

Расторгуева Т.А. История английского языка / Т.А.Расторгуева. – М.: ООО ˝Издательство Астрель˝, ООО ˝Издательство АСТ˝, 2002. – 352 с.

**Шакурова Муслима Магесумовна**
Институт языка, литературы и искусства
им. Г.Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан
УДК 811.512.145 (075.2)

# Татар лингвометодика мәктәбе һәм яңа дәреслекләргә куелган таләпләр

*татар лингвометодика мәктәбе, чорларга бүленеш, үрнәк программалар, яңа дәреслекләр һәм таләпләр, медиаматериаллар, видеодәресләр*

Татар лингвометодика мәктәбе 200 елдан артык тарихка ия. XVII гасыр ахыры XX гасыр башларында телгә өйрәтү методикасына үзләреннән өлеш керткән, бу өлкәдә тирән эз калдырган бер төркем методистлар бар: И.Хәлфин, И.Гиганов, А.Троянский, А.Казем-бек, Г.Ваһапов, М.Бикчурин, Н.И.Ильминский, М.Махмудов, М.Иванов, С.Кукляшев, К.Насыйри, Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди һ.б.).

Татар халкының мәгариф тарихы Болгар чоры белән бәйләнгән [Заһидуллина 2000: 19; Хузиахметов 2010: 9-88]. Болгарлар тыныч хезмәт белән шөгыльләнгәннәр: кыяклы, бөртекле культуралар иккәннәр, зур-зур мәчетләр, мәктәпләр салганнар, зәркән эшләнмәләр ясаганнар, күн һәм мех әйберләре эшкәрткәннәр [Кәримуллин 1991: 80]. Димәк, татар халкының мәктәп-мәдрәсәләр тарихы ислам дине белән бәйләнгән. Дөньяга караш теологик булганлыктан, белем алу да дини характерда барган [Заһидуллина 2000: 22].

Мәдрәсәләрдә дин сабагы белән бергә дөньяви фәннәр дә укытылган. Казандагы “Мөхәммәдия”, Оренбургтагы “Хөсәения”, Уфадагы “Галия”, Вятка губернасындагы Иж-Буби мәдрәсәләрендә уку-укытуның яңа алымнарын кулланганнар. Бу мәдрәсәләрдә бик күп татар зыялылары белем алган һәм шунда ук күбесе укыткан да: Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, К.Насыйри, Р.Фәхреддинев, Г.Ибраһимов һ.б.

Татар лингвометодика мәктәбенең тарихын нигездә алты чорга бүлеп карыйбыз: татар телен укыту методикасының нигезе салынган чор, методиканың чәчәк аткан чоры, укыту методикасының торгынлыкка эләккән чоры һ.б. [Шәкүрова 2012: 9]. Кыскача гына һәр этапка тукталып үтәбез.

**Беренче чор – 1740–1804.** Бу чорда татар телен укыту методикасының нигезе салына: беренче сүзлекләр, грамматика китаплары дөнья күрә. XVIII гасырда яшәп килгән гимназияләрдә татар теле дә укытыла. Беренче укытучы итеп татар бистәләренең депутаты һәм адмиралтейство конторасының тылмачы Сәгыйть Хәлфин билгеләнә. Ул ˝Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов˝ (1778) дигән хезмәт яза. 1804 елда Казан университеты ачылу да зур вакыйга була.

**Икенче чор – 1804–1890.** Бу чорның үзен икегә бүлеп карап булыр иде. Биредә рус-татар мәктәпләренең эшчәнлеге аеруча игътибар үзәгендә тора. Нигездә, рус телендә сөйләшүчеләр өчен сөйләүлекләр, үзөйрәткечләр, грамматика китаплары чыга. Әлеге чорда К.Насыйриның татар һәм урыс телләрен укытуга керткән өлешен дә ассызыклап үтәргә кирәк (“Нәхү: Русча өйрәнүче мөселман егетләре вә татарча өйрәнүче рус егетләре өчен тәсниф кыйлынды” (1860), ˝Әнмүзәҗ˝ (1895)). Шулай ук татар телен гыйльми өйрәнүгә, татар телен укыту методикасын үстерүгә зур өлеш керткән Казан лингвистика фәнни мәктәбенең роле дә, һичшиксез, зур (В.Радлов, Н.Катанов, И.А.Бодуэн де Куртенэ, В.А.Богородицкий һ.б.).

**Өченче чор – 1890–1917**. Бу чорда рус һәм татар мәктәпләре өчен дә дәреслек хезмәтен башкарган әлифбалар, үзөйрәткечләр, грамматика китаплары, методик кулланмалар чыга. XX гасыр башында татар милли әдәби телен укыту өчен бик күп татарча дәреслекләр языла (Г. Ибраһимов ˝Татар сарыфы˝, ˝Татар нәхүе˝ (1911), Г. Сәгъди ˝Үз телемезчә мөкәммәл сарыф-нәхү˝ (1915) һ.б.). Татарча уку-язуга өйрәтү методикасын үстерүдә Г. Ибраһимовның 1916 елда язган ˝Татар телен ничек укытырга? (Телебезнең

методикасы хакында бер тәҗрибә)˝ исемле хезмәтенең гыйльми һәм гамәли әһәмияте зур була. Ниһаять, татар мәктәпләре өчен дә лингводидактик хезмәтләр чыга башлый.

**Дүртенче чор – 1917–1941.** Татар телен укыту методикасының чәчәк аткан чоры (М.Х.Корбангалиев, Р.С.Газизов, Х.Г.Бәдигый һ.б.). Бу чорда Октябрь революциясеннән соң татар мәктәпләрендә татар телен һәм әдәбиятын укытуның яңача куелышын, татар телен гамәлгә кую мәсьәләләрен күз уңында тотарга кирәк. Күренекле педагог, методист, тел галиме һәм җәмәгать эшлеклесе Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиевнең халык мәгарифен үстерүдә роле зур. Аның мирасы гаять зур һәм күпкырлы: әлифбалар, дәреслекләр, методик кулланмалар, программа һәм сүзлекләр, грамматика китаплары һ.б. Аның белән иңгә-иң торып эшләүчеләрдән Р.С.Газизов, Х.Г.Бәдигый да әйтеп үтәргә кирәк.

**Бишенче чор – 1941–1990.** Татар телен укыту методикасының торгынлыкка эләккән чоры. Бу чорда татар теле фән буларак ныклап эшкәртелә, ә методик якка азрак игътибар бирелә (М.Ш. Галлямованың ˝Сөйләү телен үстерү методикасы˝ (1944), ˝Татар теле методикасы˝ (1945), ˝Башлангыч мәктәпләрдә татар теле методикасы˝ (1950), М.Ә.Фазлуллинның ˝Татар теле методикасы˝ (1954), Б.М.Мифтаховның ˝5–7 нче классларда грамматик анализ методикасы˝ (1960), ˝Татар теле синтаксисын укыту методикасы˝ (1968) һ.б). 1970–80 елларда татар телен укыту методикасына зур өлеш керткән методистлар һәм тел галимнәре, педагоглар арасында М.И.Мәхмүтов, М.З.Зәкиев, Д.Г.Тумашева, З.М.Вәлиуллина, Г.Ф.Саттаров, В.Х.Хаков, Ф.С.Вәлиева, Ф.Й.Йосыпов, Р.А.Юсупов, Ф.С.Сафиуллина, Б.М.Мифтахов, С.М.Ибраһимов, Ф.М.Хисамова һ.б. бар.

**Алтынчы чор – 1990–2020.** XX гасырның 80–90 нчы елларында илдә барган иҗтимагый яңарыш мәгариф өлкәсенә, шул исәптән рус телле балаларга татар телен укыту методикасы фәненә дә үзгәрешләр алып килде (А.Ш.Әсәдуллин, Ф.Ю.Йосыпов, Р.А.Юсупов, Ф.С.Сафиуллина, Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, И.Л.Литвинов, Р.Р.Җамалетдинов, М.М.Шәкүрова, К.С.Фәтхуллова, Р.З.Хәйдәрова, Р.Р.Нигъмәтуллина һ.б.). Татар телен гамәлгә кую барышында аны укытуның эчтәлеген, максат-бурычларын төгәлләштерү, ысул һәм алымнарын төрләндерү, камилләштерү, яңа буын дәреслекләр һәм программалар төзүгә карата яңа таләпләр куелды. Татар теленнән белем бирүнең сыйфатын арттыру теоретик материалны аңлату барышында, белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уятуны һәм дөрес итеп сөйләшергә, укырга һәм язарга, фикерләргә өйрәтүне таләп итә. Татар телен укытуның сыйфатын күтәрү, башлангыч сыйныфтан алып туган телне эзлекле үзләштерү, сөйләмне дөрес төзеп, әдәби тел нормаларына туры китереп, телдән һәм язма рәвештә башкаларга җиткерә белү – бүгенге көн уку-укыту мәсьәләләреннән иң мөһиме. Бу чорда татар теленә өйрәтү өч юнәлештә бара: 1) татар урта гомуми белем бирү оешмаларында татар телен өйрәтү; 2) рус телендә белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә өйрәтү; 3) рус телле балаларга татар телен өйрәтү.

Әлеге чорда күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итүдә Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты да катнаша. 2016 елда ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карары белән әлеге институтта милли мәгариф бүлеге оештырылды. Биредә 1-4, 5-9, 10-11 сыйныфлар өчен “Туган тел (татар теле)” предметыннан 5 яңа Үрнәк программа (ПОП) эшләнә. Алар, экспертиза үтеп, Федераль Дәүләт Үрнәк программалары реестрына кертелде. Яңа программаларга нигезләнеп, үрнәк эш программалары булдырылды. Үрнәк эш программалары сыйфатлы белем алуга бердәй мөмкинлек, уку-укыту процессын оештыру шартларына бердәй таләпләр, белем алу нәтиҗәләрен бәяләүгә бердәй алымнарны тәэмин итәргә тиешләр. Биредә белем алуның планлаштырылган нәтиҗәләре уку предметының үзенчәлеген исәпкә алып, яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә эшләнде.

Үрнәк программаларга нигезләп, “Туган тел (татар теле)” предметыннан 1-4 сыйныфлар, 5-9 сыйныфлар өчен төзелгән яңа УМКлар (авторлары – М.М.Шәкүрова, Л.М.Гыйниятуллина, О.Р.Хисамов) федераль исемлеккә керде. Яңа дәреслекләрнең

элегрәк эшләнгәннәреннән төп аермаларыннан берсе – аларда ике юнәлеш берләштерелүдә. Ягъни дәреслек ике өлештән тора. База өлеше рус телендә белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә укучыларны укытуны, тирәнтен өйрәнү өлеше татар урта гомуми белем бирү оешмаларында татар телен өйрәтүне күздә тота.

Дәреслекләрнең эчтәлеге дә үзгәрде. Аерым алганда, “Туган тел (татар теле)” предметыннан эшләнгән дәреслектә һәр сыйныфта тематик материал үзара бәйләнгән дүрт зур лексик темага берләштереп бирелә: “Мин”, “Тирә-як, көнкүреш”, “Туган җирем”, “Татар дөньясы”. “Мин” темасы укучының әйләнә-тирә дөньяга шәхси мөнәсәбәтен формалаштыруны нигез итеп ала. “Тирә-як, көнкүреш” темасы дөньяны танып-белү белән бәйле; биредә, мәсәлән, яраткан уеннар, фильмнар, туган як табигате, Интернет челтәрендә аралашу, заманча мода һ.б. балалар өчен кызыклы булган текстлар файдаланыла. Өченче тема “Туган җирем˝ дип атала. Ул татар халкының гына түгел, Россиядә яшәүче башка халыкларның да тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре белән танышу аша укучыларда патриотизм, Ватанны ярату һәм хөрмәт итү хисләрен ныгытуга юнәлдерелгән. “Татар дөньясы” блогы татар халкының традицион һәм югары мәдәнияте, тарихы, дөньяга карашы, татар фәлсәфәсе турында күзаллаулар булдыру бурычын куя. Һәр тематик блог укучыларның сөйләм телен үстерүгә юнәлтелгән. Гомумән, кунак чакыру һәм аның белән бәйле сөйләм репликалары, Идел буенда яшәүче башка халыкларның милли ашлары, өс киемнәре, музыка уен кораллары, җырлары белән бәйләп, халыклар арасында дуслык, туганлык хисләрен саклау, бер-береңне хөрмәт итүгә ирешүне укучыга кечкенәдән сеңдерерү зарур. Г. Тукай сүзләре белән әйткәндә, ˝бала янында күбрәк булырга, аның берлә шөгыльләнергә, йөрергә, бигрәк тә аның белән күбрәк сөйләшергә˝ кирәк. Элегрәк тел турында гомуми мәгълүматлар үзләштерүне күздә тоткан лингвистик компетенция формалаштыруга өстенлек бирелсә, хәзерге вакытта укучыларның аралашу осталыгын үстерү юнәлтелгән, көндәлек сөйләшүгә нигезләнгән, халык авыз иҗаты белән баетылган коммуникатив, социомәдәни, этномәдәни компетенцияләр алгы планга чыкты.

Яңа УМКлар дәреслек, эш дәфтәре, укытучы өчен методик кулланма, аудиодиск һәм электрон дәреслектән тора. Заманча эшләнгән дәреслекләр укучыны ана телендә дөрес, камил сөйләшергә, аралашырга өйрәтү бурычына җавап бирә. Дәреслек текстларның эчтәлегенә туры килгән матур, зәвыклы, заманча рәсемнәр белән бизәлгән, кызыклы уеннар, башваткычлар белән баетылган [Шәкүрова 2018: 19].

Бүгенге көндә укучылар “Туган тел (татар теле)” предметыннан эшләнгән төрле видео, медиаматериаллар, электрон белем бирү ресурсларыннан иркен файдаланалар. Әлеге предметлар буенча электрон белем бирү платформаларында эшләү мөмкинлеге дә булдырылды.

